АЛДАН САНЫЙСЫ

«ВТ» хәбәрчесе пенсия акчасын исәпләп карады

> 6

ТАТАРСТАН СЫЕ

Чаллы эшмәкәре Лисичанскида көнгә 5 мең кешене ашата

> 17

АСИЯ ЮНЫСОВА:

«Үз «начар»ыңның да яхшы сыйфатын күрә белергә кирәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 182 (28955) | Җомга | 9 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131

ОНЛАЙН ДАРУ

ИНТЕРНЕТТАН ДӘВА ЭЗЛӘҮ НӘРСӘСЕ БЕЛӘН КУРКЫНЫЧ?

Берсе фәлән дару ярдәмендә яман чирдән коткарырга вәгъдә итә. Икенчесе витаминлы эремә белән иммунитетны ныгытмакчы. БАД эчертеп, балага узарга ярдәм итәргә теләүчеләр дә шактый. Халыкны социаль челтәр аша дәваларга маташкан «белгеч»ләр тәкъдим иткән могҗизаларның берничәсе генә әле бу. Аларга ышану нәрсәсе белән куркыныч? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Яшь белгечләрне эшкә ала торган медицина оешмаларына 6 миллиард сум акча биреләчәк. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко сүзләренчә, түләүләрне билгеләү турында документ проектлары декабрь ахыры – гыйнвар башында кабул ителәчәк. Берничә көн элек Президент Владимир Путин киләсе елның гыйнварыннан сырхауханәләрдә эшләүче медикларга өстәмә акча түләнәсен әйткән иде. Өстәмә акчаның күләме – 4,5 мең сумнан 18,5 мең сумга кадәр.

Татарстанда быел гыйнвардан октябрьгә кадәрге чорда барлыгы 22,1 миллиард сумлык автокредит бирелгән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда 40 процентка кимрәк бу. Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматына караганда, республика машина сатып алуга бирелгән кредит күләме буенча 39 төбәк арасында 5 нче урынга чыккан. Беренче урында – Мәскәү: анда 9 ай эчендә җәмгысы 58,9 миллиард сум (узган елның гыйнвар – октябрь чорындагыга караганда 49,2 процентка кимрәк) кредит бирелгән. Беренче унлыкка шулай ук – Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург, Краснодар крае, Башкортстан, Ростов, Чиләбе, Свердловск һәм Түбән Новгород өлкәләре кергән.

Татарстанда декабрь башына хас булмаган суыктан соң, ниһаять, җылыта. Шимбә, якшәмбе – 10 һәм 11 декабрьдә көндез һава температурасы –3...–10, төнлә –5...–12 градус чикләрендә тирбәләчәк. Көнчыгыш төбәкләрдә –16 градуска кадәр булачак. Ялларда республиканың күпчелек өлешендә кар-буран булыр, дип фаразлана. Киләсе атна башында болытлы һава урнашачак. Карлы яңгыр, урыны белән бозлавык. Көндез –2...–7, төнлә –4...–9 градус.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** **444 сум 54 тиен**

гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** **980 сум 10 тиен**

гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

АЧЫК ҺӘМ ГАДЕЛ БУЛСЫН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Коррупциягә каршы халыкара көрәш көне уңаеннан мөрәҗәгате

Дөнья ыргылышлы төстә үзгәрә һәм бу, һичшиксез, сәяси, икътисади һәм социаль өлкәдә яңа сынаулар, яңа киенлекләр китереп чыгара. Килеп туган шундый шартларда Россия Федерациясе үзенең көчен, мөстәкыйльлеген һәм икътисади суверенитетын ныгытуга юнәлеш тота.

Татарстан, күпмилләтле Ватаныбыз белән бергә, тышкы һәм эчке сынаулар аша уза. Россия Федерациясенә күмәк санкцияләр басымы шартларында республика хакимиятенең барлык баскычлары, ил җитәкчелегенә һичшиксез теләктәшлек белдереп, көйле эшләвен дәвам итә. Татарстан җитештерү комплексының озак еллар буе өзлексез эшләве елларында булдырылган ныклы нигезе, кеше капиталы һәм нык үсешле инфраструктурасы ярдәмендә үзенең үсешен саклап кала. Без республиканы үстерүдә күпмилләтле халкыбызның төп урынны алып торуын аңлап, социаль гарантияләрне тәэмин итәбез, кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән илкүләм проектларын һәм республика программаларын эзлекле төстә тормышка ашырабыз.

Татарстанда яшәүчеләрне идарә итү карарлары кабул итүгә җәлеп итү республиканы үстерүдәге гарантларның берсе булып тора. Барлык дәрәҗәләрдәге муниципаль хакимият органнары халык белән нәтиҗәле төстә берлектә эшләүне җайга салуда мөһим роль уйный. Нәкъ менә алар җәмгыять белән даими диалог шартларында кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү бурычын хәл итә.

Цифрлаштыру дәүләт органнары эшенең үтәкүренмәлелеген булдыруда нәтиҗәле чарага әйләнеп килә. Ел ахырына кадәр барлык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерүне төгәлләргә ниятлибез. Бу республикада яшәүчеләргә хезмәтләр күрсәтүдәге ачыклык һәм контрольне көчәйтү мөмкинлеге бирәчәк.

«Халык контроле» һәм «Инцидент-менеджмент» мәгълүмат системалары башкарма органнар эшчәнлегенең ачыклыгын көчәйтү һәм коррупцион куркынычларны киметү чаралары исәбенә керә. Алар халык белән кире элемтә булдыру, кешеләргә күп кенә мәсьәләләрне хәл кылуда катнашу һәм үзләренең фикерен белдерү мөмкинлекләрен бирә. Әлеге платформаларны алга таба да кулланырга һәм үстерергә ниятлибез.

Кеше һәм аның дөньяга карашы, гадәттәгечә, игътибар үзәгендә калып килә. Республикада иҗтимагый институтларны үстерү бурычлары системалы төстә үтәлә. Бу максаттан чыгып, халык арасында массакүләм мәгълүмат чаралары аша законны ихтирам итү, хокукый нигилизмны җиңү һәм коррупциянең теләсә кайсы формасын кабул итмәү кебек кыйммәтләрне булдыруга юнәлдерелгән агарту эше алып барыла. Мәгариф оешмаларында балалар һәм яшьләрне рухи-әхлакый яктан, ватанпәрвәрлек рухында һәм коррупциягә каршы рухта тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар күрелә. Казан (Идел буе) федераль университеты каршында дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе эшләп килә. Ул үз өлкәләрендә идарә итү осталыгына ия булган югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә юнәлдерелгән квалификация күтәрү программаларын тормышка ашыра. Һәр ел саен әлеге программалар буенча 5 меңгә якын кеше белем эсти.

Коррупциягә каршы халыкара көрәш көнендә тормыш эшчәнлегенең икътисади һәм социаль өлкәләрендә коррупцияне булдырмас өчен барлык чараларны эзлекле төстә кабул итүгә әзер торуыбызны белдерәбез һәм республикада яшәүчеләрнең коррупциягә каршы сәясәтне хуплавына ышанабыз.

ЭШЛӘГӘНГӘ ЭШ БАР

«Казан Экспо»да бүгенге шартларда кайсы якка бару турында фикер алыштылар. Татарстан Машина төзелеше форумында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Донецк Халык Республикасы башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Денис Пушилин, Россия Хәрби-сәнәгать комиссиясе коллегиясе әгъзасы Вячеслав Шпорт та катнашты.



tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов Донецк Халык Республикасы башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Денис Пушилин белән Казан Кремлендә дә очрашты. Президент әйтүенчә, Татарстан Луганск Халык Республикасы белән Лисичанск шәһәрен торгызу буенча хезмәттәшлек итә. ДНР белән дә эшләргә әзер. Очрашуда уртак эш юнәлешләре турында сөйләштеләр.

– Безнең мөмкинлекләр Ватаныбыз үсеше өчен файдалы булачак. «Донбасс ул –күмер һәм металлургия гена» дигән фикер бар. Болар белән беррәттән, бездә машина төзелеше дә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булды. Бүген җитештерүне күтәрү юнәлешендә эшлибез. Тармакта хәзерге шартларда саклап калган 70тән артык сәнәгать предприятиесе бар. Россия Федерациясенә кушылгач, безгә зур мөмкинлекләр ачылды, – диде Денис Пушилин, Казанга килгәч. Ул Татарстан белән төбәкара хезмәттәшлекне үстерү белән кызыксынуын әйтте һәм Донбасска даими ярдәм итеп торулары өчен, республика халкына рәхмәт сүзләрен җиткерде.

– Безнең алда илнең технологик бәйсезлеген тәэмин итү бурычы тора. Җитештерелә торган продукцияне бер урынга җыю, ил эчендә чимал белән тәэмин итүчеләрне эзләп табу мөһим. Форум сәүдәне киңәйтү, инновацияле технологияләрне гамәлгә кертү турында фикер алышу, яңа килешүләр төзү кебек юнәлешләрдә ярдәм итәр, дип ышанам, – диде Президент.

Пленар утырышта сүзне дәвам иттереп, фәнни-техник һәм сәнәгать потенциалын үстерү, үз технологияләребезне һәм инфраструктураны булдыру, импортны алмаштыруга бәйле бурычлар турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, бүген республикада 3,5 меңгә якын машина төзелеше предприятиесе эшли. Тармакта 120 мең кеше хезмәт итә. Төрле санкцияләр кертелүгә дә карамастан, республика үсеш күрсәткечләрен саклап кала алган. Ел азагына кадәр машина төзелеше предприятиеләре 800 миллиард сумлык продукция җитештерәчәк дип фаразлана.

«Махсус хәрби операция оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре алдына яңа бурычлар куя. Кыска вакыт эчендә гаскәрләрне заманча корал һәм техника белән тәэмин итәргә кирәк. Бүген республика предприятиеләре әлеге мөһим бурычны хәл итүдә катнаша һәм дәүләтебез иминлеген тәэмин итүгә үз өлешен кертә», – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул Беларусь, Казахстан, Төркия һәм башка илләрдәге хезмәттәшләребез белән эшне көчәйтергә кирәклеген дә әйтте.

Чит илләрнең зур компанияләре китү белән ил базарында үзебезнең машина төзелеше предприятиеләре өчен яңа мөмкинлекләр ачылуын да билгеләп уздылар. Республика предприятиеләре бу юнәлештә эшли башлаган инде. Мәсәлән, «КАМАЗ» киләсе елда К5 төрендәге машиналар җитештерүне яңадан эшләтеп җибәрергә ниятли. «Соллерс» компаниясе җиңел коммерцияле автомобильләр җитештерү буенча яңа проект тормышка ашыра. Беренче «тимер ат»ларны Яңа елга кадәр үк сата башларга җыеналар. «Алабуга автомобиль заводы» заманча грейдерлар һәм бульдозерлар җитештерүне үзләштергән.

Вячеслав Шпорт сүзләренә караганда, санкция шартларында мондый чара аеруча да зур әһәмияткә ия. «Безгә бөтен яктан да басым ясыйлар, югары технологияле җиһазлар белән тәэмин итүгә комачау итәләр. Моңа да карамастан, безнең предприятиеләр үз сәнәгатен һәм технологияләрен үстерә. Импортны алмаштыру ул – Россия сәнәгать сәясәтенең нигезе, социаль-икътисади үсешебезнең мәҗбүри шарты», – диде Мәскәү кунагы.

ТОРМЫШНЫ ЯХШЫРТУЧЫЛАР

Башкалада республика төзелеш тармагының 100 еллыгына багышланган тантаналы чара узды. Бәйрәмгә төзүчеләрдән дә бүләк бар: моңарчы тиңе булмаган мәйданда торак төзегәннәр.

Чарада Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. Тагын бер якташыбыз – Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин республика төзүчеләрен видеоэлемтә аша котлады. «Татарстан төзүчеләрен һәрчак һөнәри осталык һәм эшләренең югары сыйфаты аерып торды. Минем өчен бу юбилей аеруча да мөһим, чөнки ун ел Татарстан төзелеш министры булып эшләдем», – диде Россия вице-премьеры. Ирек Фәйзуллин Татарстан Төзелеш министрлыгын илдә иң көчлеләрнең берсе дип атады. «Республиканың төзелеш тармагында оешкан система алга таба да уңышлы эшләвен дәвам иттерсен», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, төзелеш республика икътисадының төп тармакларының берсе булып тора. Шулай булмый ни! Төзүчеләр эш белән шаккатыра әнә. Татарстан тарихында тәүге тапкыр файдалануга тапшырылган торак мәйданы 3 миллион квадрат метрдан артып киткән. Былтыр төзелеш тармагында 97 миллиард сумлык дәүләт программалары һәм чаралар тормышка ашырылган. «100 ел эчендә республикада Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Иннополис кебек шәһәрләр калкып чыкты. Архитекторларыбыз, төзүчеләребез, гомумән, үз эшенең осталары белән хаклы рәвештә горурланабыз!» – диде Президент. Ул тармак ветераннарын һәм хезмәт династияләрен аерым билгеләп үтте. «Кеше һәрвакыт тормыш шартларын яхшырту өчен төзелеш алып барган. Яңа төзелеш материаллары, технологияләр барлыкка килә, әмма төзүчеләрнең миссиясе шул ук. «Тормышны тагын да яхшыртырга!» Бу шигарь бүген дә республиканың үсеш максатлары белән туры килә. Архитекторлар һәм төзүчеләр тырышлыгы белән республика шәһәрләре һәм авыллары үзгәрә. Барлык төзүчеләргә дә бердәм булып эшләүләре өчен рәхмәт әйтәсем килә», – диде республика башлыгы.

Чара кысасында Рөстәм Миңнеханов Ирек Фәйзуллин белән дә очрашты. Сөйләшү барышында Татарстанда федераль һәм республика проектларын гамәлгә ашыру турында фикер алыштылар. Кичә 60 яшен тутырган Ирек Фәйзуллинны Казаннан буш кул белән җибәрмәделәр. Федераль министрга «Дуслык» орденын тапшырдылар.

КИЛӘЧӘК ӨЧЕН КИРӘК

Казанда Бөтендөнья табигый һәм мәдәни мирасны саклау конвенциясенең 50 еллыгына багышланган халыкара форумның йомгаклау утырышы узды. 5 декабрьдә башланган чарада дөньяның 56 иленнән белгечләр катнашты.

Чарада катнашучыларны республика Хөкүмәте исеменнән Татарстан Премьер-министры урынбасары Шамил Гафаров сәламләде. Белгечләргә башкарылган эш өчен рәхмәт сүзен дә кызганмады һәм кабат кунакка чакырды.

– Әлеге чара Татарстан өчен аеруча мөһим. Форум кысасында дөньяның 56 иленнән җыелган белгечләр киләчәк буын кулларына тапшырылачак мәдәни һәм табигый мирас һәм әлеге мәсьәләгә кагылышлы актуаль проблемалар турында уртага салып сөйләште. Аларның Татарстанга килүе – безнең өчен зур җиңү, – диде ул. – Татарстандагы өч объект ЮНЕСКО исемлегенә кертелде. Без моның белән горурланабыз, әмма туктарга җыенмыйбыз. Бу юнәлештә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тарафыннан зур эш башкарылды. Аның эшен Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов дәвам иттерә.

Гомумән алганда, форум кысасында җиде конференция һәм ЮНЕСКОның яшьләр моделе узды. Белгечләр сәнәгать объектлары мирасы, Сүриядәге борынгы Пальмираны торгызу, Бөек ефәк юлы һәм табигый-мәдәни мирас өлкәсендәге башка мәсьәләләр турында фикер алышты. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән яшьләр исә, «Адымнар» мәктәбендә очрашып, үз җирлекләрендәге ЮНЕСКО исемлегенә кертелергә лаеклы урыннар турында сөйләште. Йомгаклау утырышында алар, барысы бергә сәхнәгә чыгып, мондый фикер алышуларны ел саен уздырырга кирәк, дип, оештыручыларга рәхмәт әйтте.

Яшьләр башкарган эшне Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКО илчесе Минтимер Шәймиев тә югары бәяләде. Үз чыгышында ул, дөньялар үзгәрсә дә, вакыт белән билгеләнгән кыйммәтләрне саклап калуның әһәмиятен искәртте.

– Әлеге форумда катнашып, сез бу өлкәдә бергә эшләргә һәм карарларны да бергә кабул итәргә әзер булуыгызны күрсәттегез. Безнең бурыч – тагын да нәтиҗәлерәк эшләү. Бу бит – безнең генә түгел, бөтен Җир шарының киләчәге өчен башкарыла торган эш, – диде Минтимер Шәймиев. – Үзегез дә күрдегез: бу чараны булдырмый калырга тырышучылар шактый иде. Әмма Татарстанның девизы – «Без булдырабыз!» Шуңа да без моңа юл куя алмадык. Ә бит ЮНЕСКО яраклашучы түгел, ә әйдәп бара торган көч булырга тиеш.

Йомгаклау утырышында форум кысасында узган һәр конференциянең нәтиҗәсе белән таныштырдылар. Ә форумның йомгаклау декларациясен Россиянең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе җаваплы сәркатибе Георгий Орджоникидзе укыды. Нәтиҗәдә декларация 10 пункттан артып киткән.

– Билгеле, бу әле – тәгәлләнгән документ түгел. Барлык максатларга ирешмәсәк тә, форум кысасында зур эш башкарылды. Һәр юнәлеш үз резолюциясен тәкъдим итәр дип уйлыйбыз, – диде ул, журналистлар белән аралашканда.

Каләм сүзе

Миллилек югалмасын өчен. «Татмедиа» республика агентлыгында Татарстанда яшәүче халыкларның мәдәниятен, телләрен, традицияләрен саклау һәм үстерүгә өлеш керткән матбугат чараларын бүләкләделәр.

Агентлык җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев сүзләренчә, милли проектлар өчен грант алу бәйгесенә 56 редакциядән гариза юлланган һәм шулар арасыннан 34 проект сайлап алынган. Җиңүчеләрне Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов котлады.

– Матбугат эшчәнлеге мәсьәләсендә беренди һөнәри осталыгым да юк, әлбәттә. Безнең максат беренчедән, сезнең үзегезне тел, традицияләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләренә кызыксындырып тартып кертү, икенчедән, милләттәшләребезнең күңеленә барып җитү иде. Бу проектларның ни дәрәҗәдә отышлы булганын вакыт күрсәтер, әмма без дөрес юлда дип саныйм. Шушы эшне киләчәктә дә дәвам иттерергә кирәк, – диде Марат Әхмәтов журналистларга. – «Татмедиа» агентлыгы яңа юнәлешләр тәкъдим итә икән, без бишкуллап кабул итәбез. Яңа чаралар, алымнар, үтемле сүзләр белән милләттәшләребез күңеленә күбрәк барып җитәргә кирәк. Безнең иң зур аудиториябез – сезнең аша. Ул мәдәният йортына музыкаль яки башка программа карарга җыелган 300–500 кеше генә түгел, ә дистәләгән, йөзләгән мең укучы һәм тамашачы. Үз өстегездә эшләп, яңа алымнар эзләгәнсез, киләчәктә дә бу кирәкле эшне бергә дәвам иттерик.

Теманың дәвамы 15 нче биттә >

ТЕРӘК ҺӘМ ҮРНӘК

Бүген – Ватан Геройлары көне. Бу уңайдан республикада яшәүче Геройларны Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин котлады.

«Иң зур бүләк – Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт һәм Россия Федерациясе Хезмәт Герое исеменә лаек булган фидакарьләргә, Сугышчан һәм Хезмәт даны орденнарының тулы кавалерларына дәүләт, җәмгыять ягыннан иң югары дәрәҗәдә ихтирам хисе белән сугарылган бәйрәм бу, – диелә котлауда. – Без бу көнне Ватаныбыз хакына, үзләренең туганнары һәм якыннары хакына батырлык кылган, тырыш хезмәте белән илебезнең данын һәм бөеклеген тагын да югарырак баскычка күтәргән чын мәгънәсендә ватанпәрвәрләр алдында баш иябез. Мондый кешеләрнең тормышы – яшь буынны ватанпәрвәрлек һәм илебезгә тугрылык рухында тәрбияләү үрнәге. Батыр ватандашларыбыз бүген дә Россия мәнфәгатьләрен яклап, хәрби осталык, кыюлык һәм батырлык үрнәкләрен күрсәтеп, үзләренең хезмәт бурычын фидакарьләрчә үти. Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре, яңа продукция булдыру максатында, киеренке эшли. Геройларыбызны данлап, аларга чын күңелдән сәламәтлек, бәхет, иртәгәсе көнгә ышаныч телим! Җиребездә һәрчак тынычлык һәм татулык булсын!»

Дәүләт Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүгә эшлекле сәфәре кысасында Россия Закон чыгаручылар советы һәм аның Президиумы утырышында катнашты.

Федерация Советында узган беренче утырышта бүгенге шартларда Россияне, аның төбәкләрен социаль-икътисади яктан үстерү турында сөйләштеләр. «Бүгенге вазгыятьтә барлык хакимият органнары, беренди дә хатага юл куймыйча, көйле эшләргә тиеш», – диде Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко. Аның сүзләренә караганда, бүген Россиянең яңа субъектларына ярдәм итү дә бик мөһим. Төп эшләрнең берсе – аларны илнең хокук һәм икътисад системасына кертү.

Закон чыгаручылар советы Президиум утырышында исә федераль һәм төбәк парламентчылары әһәмиятле социаль мәсьәләләр, шул исәптән мобилизацияләнүчеләргә, аларның гаиләләренә ярдәм итү, шулай ук Россиянең хәрби-тарихи мирасын саклау турында фикер алышты.

Мобилизацияләнүчеләргә һәм аларның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм итү өчен федераль дәрәҗәдә генә түгел, төбәкләрдә дә карарлар кабул ителә.

– Татарстанда бу эш бик җитди төстә алып барыла, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Без мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә, әтиләре гражданлык бурычын үтәргә киткән балаларга ярдәм итәбез. Республика ягыннан да, муниципалитетлар ягыннан да ярдәм ителә. Биредә сүз матди генә түгел, бәлки рухи ярдәм турында да бара. Без барыбыз да ил Президенты Владимир Путин тирәсендә берләшеп, ил җитәкчелеге вакытында кабул иткән чараларның Ватаныбызны саклау бурычын ничек тә азрак югалту белән үтәүгә ярдәм итүен аңлыйбыз.

Фәрит Мөхәммәтшин Россия составына кергән яңа территорияләрдә яшәүчеләргә гуманитар ярдәм оештыручыларның һәммәсенә рәхмәт сүзләре ирештерде.

– Республикабызның күпмилләтле халкы, олысы-кечесе бу эшкә чын йөрәктән кушыла, – диде ул. – Барлыгы 600 тоннадан артык гуманитар ярдәм җибәрелде. Шәһәрләр һәм районнарда яшәүчеләрнең берсе дә битараф калмый. Бу безне берләштерә. Һичшиксез, әлеге эш, алга таба да дәвам итәчәк.

Парламентчылар Закон чыгаручылар советы Президиумы утырышы кысасында патриотик тәрбия турында да сөйләште. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, илебезнең күп кенә төбәкләрендә яшәүче Россия Федерациясе һәм Советлар Союзы Геройларының батырлыклары чын мәгънәсендә ватанпәрвәрлек үрнәге булып тора. Парламент башлыгы алар белән ешрак очрашырга, геройлар үрнәгендә яшь буынны тәрбияләргә тәкъдим итте.

Татарстанның Россиядәге Вәкаләтле вәкиллегендә узган очрашуда да бу хакта сөйләштеләр. Ватан Геройлары көне уңаеннан биредә узган очрашуда вәкиллек каршында оештырылган Офицерлар клубына керүче Россия Геройлары – Марат Алыков, Рәфыйк Ихсанов, Сергей Тулин, Игорь Уразаев, очучы-космонавт – Бөгелмә егете Сергей Рыжиков, Советлар Союзы Герое һәм Россия Герое исеменә беренче булып лаек булган очучы-космонавт Сергей Крикалев катнашты. Сүз уңаеннан, офицерлар клубына барлыгы 19 Советлар Союзы һәм Россия Герое керә.

Быел махсус хәрби операция барышында Россия Герое исеменә лаек булган Раил Габдрахманов, Иван Додосов һәм Артур Орлов Вәкаләтле вәкиллеккә тәүге тапкыр килде. Барысы да – Казан танк училищесын тәмамлаган егетләр.

«Һәркайсыгызга чын күңелдән рәхмәт. Сез – гражданлык бурычын үтәү үрнәге. Фәкать тырыш хезмәт һәм югары дәрәҗәдә ватанпәрвәрлеккә ия булу нәтиҗәсендә генә Герой исемен яуларга мөмкин», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Очрашуда катнашучыларны Россия Геройлары исеменнән Сергей Рыжиков сәламләде. «Тыныч тормышта яшәгәндә, сугышка әзерлән, сугышта – тынычлыкка әзерлән, диләр. Мондый чорга без башлыча әзер идек, әмма халкыбызның көче һәм бердәмлеге нәтиҗәсендә нинди эчке мөмкинлекләргә ия булуыбызны тормыш тагын да күрсәтәчәк әле», – диде ул.

Язучы сүзе

Чүл буйлап йөргән шикелле...

Марат
КӘБИРОВ

Ни өчен шулай икәнен әйтә алмыйм инде мин аның. Хәтта чынлап та шулаймы, әллә тоела гынамы икәнен дә төгәл белмим бугай. Бәлки, билгеле бер яшькә җитү галәмәтедер, бәлки, чорның берәр үзенчәлегедер... Бәлки, миндә генә була торган иллюзиядер... Кайчагында: «Берәр психик авыру түгелме соң бу, акылдан шашу билгесе түгелме?» – дип тә шикләнеп куям. Аннан соң тирә-якны, кешеләрне күзәтәм дә алар белән чагыштыргач бик үзгә дә түгелмен кебек тоела. Менә шундый сәер уйларга да этәрә ул кайчагында...

Гади генә нәрсә инде үзе... Менә мин урам буйлап атлап барам. Көн матур, күктә кояш елмая.Назлы буларга тырышып, җил исә. Йортлары да матур, юл буйлап әллә ничә төрле әллә нинди маркалы матур автомобильләр җилдерә. Тротуардан бер ана коляска тартып бара. Хәтәр икән хәзерге коляскалар да: карда чанасын чыгарып була, кара җиргә яки асфальтка керсәң, тәгәрмәчен җайлыйсың. Тирә-юньдә кибетләр инде. Ниндиләре генә юк, нәрсәләр генә сатмыйлар. Кереп караштырып чыгам, бөтен нәрсә дә бар. Кайберләрен сатып алам, кайсыларын кире куям. Тагын урамга чыгам.

Муллык инде бөтен тирә-якта. Кешеләрнең киемнәре күз явын алырлык. Аларга карап сокланмыйсың да, көнләшмисең дә, чөнки теләгең булса, үзең дә берәр урынга кереп, матур итеп киенеп чыга аласың. Ашханәләр, кафелар, рестораннар, хуш ис таратып, үзләренә чакырып тора. Ис чыгарулары махсус эшләнә икән, карыннары ача башлаган кешеләр шул тәмле искә алданып керсеннәр өчен. Мондый нәрсәләрне әллә нинди акыллы кешеләр уйлап таба, шуның өчен кесә тутырып акча алалар, ди. Шулайдыр. Кибетләрдәге азык-төлеккә исең китәрлек. Ниндиләре генә юк! Икмәге генә дә фәләнешәр төрле! Ите, балыгы, колбасасы, тагын әллә нәрсәләре... Тамагың тук булса да, берни ашыйсың килмәсә дә, нәрсәдер эләктереп чыгасың кайчагында.

Бер уйлап карасаң, шулкадәр матурлык һәм муллык эчендә яшибез бит. Бездәге гади кеше тормышын борынгы патшаларның берсе дә күз алдына китерә алмагандыр. Ни теләсәң, шул бар. Тик без моны уйлап та бирмибез. Бөтен нәрсәбез җитеш булса да, шөкер итү турында уй башка да кереп карамый. Хәтта башыңа керсә дә, никтер шөкер итәсе килми. Чөнки күңел сөенә белми. Ул сөенү хисеннән мәхрүм калган. Нәрсәдер җитми күңелгә. Һәм нәрсә җитмәгәнне беркем дә белми.

Баштарак мин, әллә үзем генә шундый хәлдә микән дип, бик борчыла идем. Түгел икән. Менә урамга чыгып, юри генә күзәтеп торыгыз әле сез: анда тирә-якка сокланып атлаган бер генә кеше дә юк. Барысының да йөзе киеренке, кашлары төйнәлгән, күзләре бер ноктага төбәлгән. Барысы да каядыр ашыга, алардан башка дөньяның берәр чите кителеп төшәчәк дип торырсың. Ашыгалар. Хәтта бер урында басып торганнары да, каударланып, телефон актара, калтырана-калтырана нәрсәдер яза... Шөкер итү турындагы уй исләрендә дә юк. Нәрсәдер барып сорасаң, болар башта чит планета кешесе күргән шикелле аптырап карап тора. «Кем бу? Минем дөньяма кайдан килеп кергән? Нәрсә турында сорый ул?» Шуннан кайберләре, иңнәрен җыерып, башын чайкый. Тормыш белән бәхилләшеп бетмәгәннәре соравыңа җавап бирә.

Башкаларны күзәткәндә, үзеңне күрмисең. Читтән карап торучыга мин дә шул чамарак тоеламдыр инде. Кайчагында танышларым эшләгән урыннан узып киткәлим. Якын танышлар инде алар. Күптән күрешкән дә юк. Кереп чыгарга, хәл-әхвәл белешергә була. Күп вакыт та китми инде аңа. Тик кермичә узам. Очрашсак, сүз таба алмый интегербез шикелле дә тоела. Ни турында сөйләшәсең инде? Ничә сөйләшсәң дә, шул бер үк сүз... Очрашу сөенече, бер-береңне күрү шатлыгы онытылган кебек... Икенче ягы да бар бугай аның: мине күргәч, алар да шатланмыйлар. «Тагы нәрсә кирәк икән моңа?» – дигәнрәк кыяфәт чыгаралар. Барысы да түгел инде. Тик берсенең шундый карашы барысын да алыштыра кебек. Кешеләрнең үз җае белән барган дөньясына хәл-әхвәл сорашу өчен генә бәреп керәсе килми башлый.

Шуңа күрә, шау-гөр килеп торган урамнардан урап кайтам да үземне чүлдәге кебек тоям. Көннең яме, ашның тәме юк шикелле. Чүл инде... Бушлык... Ямьсез, тәмсез, гамьсез дөнья. Коронавирус белән чирләгән кешеләр тәм тоюдан, ис сизүдән мәхрүм калалар бит әле... Монда да шундыйрак хәлдер, кешеләр канәгатьлек тойгысыннан, сөенә белү хисеннән мәхрүм калганнардыр сыман. Монысы тагын нинди вирус икән?

Бәлки, алай да түгелдер инде ул... Тик, барыбер, шатланасы килә... Шатланасы килә... Кайчагында чын шатлык та табыла, күзләр очкынлана, иреннәр елмаю җәелә. Тик аларны шундук тыярга мәҗбүр буласың. Тизрәк яшерәсең... Шундый киеренкелеккә чумган җитди кешеләр арасында елмаю да оятсызлык кебек тоела.

ФУТБОЛ ҺӘМ ЛГБТ,

ЯКИ ЧЫНЛАП ТА ИРЛӘР ҺӘМ ХАТЫННАР БАРМЫ?

Бүген Катарда бара торган гадәттән тыш кыйммәткә төшерелеп оештырылган футбол буенча дөнья чемпионаты кешелек җәмгыятенең акылдан язып баруын дәлилле торган бик күп фактларга бай. Тупны кешеләрнең кайсы төркеме яхшырак тибүен ачыклау өчен барган берничә көнлек уеннарны үткәрергә 220 миллиард доллардан артык акча чыгарып салу үзе үк түбә кыйшаюның бер билгесе булып тоелмыймы сезгә?

Юк, юк, бу юлларның авторы һич кенә дә футболга каршы түгел. Яшьлектә ул үзе дә туп тибәргә ярата иде. Әмма бөтен эшен ташлап, диванга яткан хәлдә кемнеңдер җиңүе өчен җан атып исә җиңелүе өчен йөрәге әрнеп вакыт үткәрүчеләрне аңлый алмый. Футбол бар, фанатиклык бар. Болар икесе – ике нәрсә. Сыра эчеп, корсак үстергән ирләрнең спортка ниндидер катнашы бар, дип әйтеп булмый бит инде.

Чемпионат асылда, әнә шул фанатиклыкны үстереп, массаларның аңын томалап торуга хезмәт итә. Футбол трансляциясен карау өчен, бар планета халкының күпчелеген телевизор каршына кадаклап куя аласың икән, димәк, син аларга йогынты ясый аласың, идарә итә аласың, теләсә нинди фикерне (хәтта ул аек акылга сыймый торган булса да) сеңдерә аласың. Адәм баласы гипнозлана, үз алдына «Нәрсә хакына?» дигән сорауны куйдан туктый. Әйтик, бер генә гарәп тә: «Нәрсә хакына Согуд Гарәбстанының тәхет варисы бер матчта җиңгән өчен генә җыелма команданың һәр футболчысына кыйммәтле Rolls Royce Phantom машинасы бүләк итте?» – дигән сорауны куеп азапланмый. Факт үзе исә аяк тубы тибүчеләрне (футбол татарчага шулай тәрҗемә ителә, гарәпләр «футбол» дигән сүз кулланмыйлар, «күрәтәл кадами» диләр, ягъни «аяк тубы») шундый югарылыкка күтәрә: алар символга, соклану объектына, кумирларга әвереләләр.

Чынлыкта Согуд җыелма командасы чемпионатта бик әллә ни зур уңышларга ирешә алмады. Әйтик, ярышларның 1/8 өлешендә алар юк. Гарәп илләреннән бер Марокко гына – исемлектә. Марокко җанатарлары исә чемпионатта үз илләре җыелма командасының испаннарны җиңүен француз шәһәре Лилльдә шундый итеп билгеләп үтте: юл хәрәкәте ябылды, берничә урында янгыннар чыкты, ахыр чиктә полиция белән бәрелешкә керделәр. Фанатлар һәрвакыт үзләрен шулай тота, моңа хәзер гаҗәпләнмибез дә инде.

Менә шул хәлгә китерелгән кешеләрне бозык идеяләр сеңдерү өчен файдалану бик җиңел. Хәзер Җир шарында иң зур проблема дип нәрсәне күз алдына китерәсез? Нәрсә генә уйласагыз да, ялгыштыгыз. Дөньяны үз кулларына төшереп, халыклар өстеннән коллар белән идарә иткән кебек идарә итәргә теләүчеләр сезнеңчә уйламый. Алар иң зур проблема дип ЛГБТ-җәмәгатьчелекнең хокуклары бозылуны саный. Пропаганда нәтиҗәсендә акылдан язып, җенси бозыклыкның иң түбән төрләрен яшәү рәвеше итүчеләр киң хокуклардан файдаланырга тиеш, аларны кимсетә торган сүз әйтергә ярамый, киресенчә, түбәннәрнең яшәү рәвешен байрак итеп күтәрергә кирәк. Болар хәзер – дөньяда өстенлек иткән рәсми пропаганданың төп нигез ташы. Менә карагыз: Олимпия комитеты президенты Томас Бах шундый таләп куярга җыена: «Хәзер һәр илнең җыелма командасында ЛГБТ вәкилләре кимендә ун процент булырга тиеш».

Гейлар һәм лесбиянкаларның спортка нинди катнашы бар? Бер катнашлары да юк. Бары тик спорт аша бозыклыкны пропагандалау гына җиңел һәм үтемле. Сез, бәлки, Көнбатышта гади халык «зәңгәр»ләр һәм «алсу»ларны үлеп ярата дип уйлый торгансыздыр. Күптән түгел генә Америкадагы Колорадо-Спрингс каласында урнашкан гей-клубта – ЛГБТ-культураның үзәге булган урында – һөҗүм итеп, кешеләрне атып үтерделәр һәм җәрәхәтләделәр бит әле. Аларга мәхәббәт сәбәпле эшләнмәде инде ул гамәл. Ә сәяси лидерлар һәм йогынты ияләре ЛГБТны яратырга гына түгел, кешеләрнең массакүләм шулар сафына басуына ирешергә дигән максат куйды. Шул максатка бар сәнгать хезмәт итә, балалар өчен мультфильмнарга кадәр күпләп эшләнә. Төркиядә һәм тагын 15тән артык илдә, мәсәлән, Disney студиясендә эшләнгән «Гаҗәп

pixabay.com

дөнья» дигән мультфильмны ЛГБТ пропагандалагань өчен тыйдылар. Тыелмаган мультфильмнарда да бозыклыкка өйрәтү яшерен генә кертеп җибәрелә һәм аны бездәге балалар да карый.

Америка ЛГБТ-активисты Джеффри Марш күптән түгел генә: «Биологик җенес ул – фейк», – дип игълан итте. Ягъни без, нормаль кешеләр, үзебезне ирләр, хатыннар дип уйлап, бик нык ялгышабыз. Әлбәттә, аерым бер кешенең андый сүзләрен юләрлеккә санап игътибар итмәскә дә була. Соңгы көннәрдә генә Россиянең Оттавадагы илчесе Олег Степановны Канаданың Тышкы эшләр министрлыгына чакырып «пешекләделәр». Ул «Твиттер»да бер комментарийда Канаданың спорт министры, лесбиянка булганын яшермәүче Паскаль Сент-Онжның бу дөньяга ничек килүен исенә төшергән. Бары шул гына.

Күрә торгансыздыр: спорт һәм ЛГБТ бик тыгыз бәйләнгәннәр. Катардагы футбол буенча дөнья чемпионатында да бу ачык күренде. Катар, ни дисәң дә, мөселманнар яши торган ил бит инде, шуңа күрә гей-активистларга һәм үзара сөешүче хатыннарга анда туарылырга бик үк ирек бирмәделәр. Көнбатыш журналистлары һәр адымда мөселманнарның бу җәһәттән артта калган булуларын, кеше ирегең кысуларын искә төшерергә, уклар атарга тырышты. Катарның энергетика министры көнбатышлы репортер белән әңгәмә вакытында: «Сез безгә туристлар буларак килә аласыз. Проблема юк. Ләкин сез мине: минем динемне, минем иманымны үзгәртергә, минем илемдә минем гаиләм Көнбатышка ярарга тырышып кына гомосексуалистларның хокукларын хөрмәт итәргә, ислам законнарын үзгәртергә тиеш дип расларга телисез икән – монысы беркайчан да булмас», – диде.

Шуңа карамастан, чемпионат мәйданын ЛГБТ-пропаганда урынына әверелдерү омтылышлары барыбер булды. Португалия – Уругвай матчы вакытында уен кырына ЛГБТ флагы күтәргән бер ир йөгереп чыкты. Германиянең җыелма командасы, кырга тулы составта чыкканда, авызларын каплап чыкты, янәсе, гей-пропаганда тыелу уңаеннан телләрен тешлиләр. Аларга җавап итеп атаклы Катар докторы Хәммүд ән-Нәүфәли: «Катар сезгә авызларыгызны капларга кушмады. Катар сездән лаеклы ирләр булып калу өчен башка урыннарыгызны каплауны һәм немец җәмгыятен демографик үлемнән коткаруыгызны сорый», – диде. Чынлап та, ЛГБТ таралган илләрдә демографик кризис куркыныч масштаблар ала. Бозыклык байрагын югары күтәргән Канада 2025 елдан башлап ел саен үзенә 500 мең мөһаҗир китерергә планлаштыра, чөнки балалар аз туу сәбәпле, икътисадны үстерергә эшче куллар җитешми. Башка Көнбатыш илләре дә шундый ук проблемалар кичерәләр.

Кешегә бертуктаусыз «син дуңгыз» дип кабатлап торсаң, ул, чынлап та, үзен дуңгыз дип тоя башлый, диләр. ЛГБТ-пропаганда нәкъ менә шуңа исәп тота да: мөмкин булган барлык тишекләрдән дә «ирләр юк, хатыннар юк» дигән тавышлар ишетелә. Моңа шик белдерүчеләр, томана, иреккә кысучылар, дип тамгалана. Массаларны үзенә иң күп җәлеп итүче спорт ярышлары мәйданы нәкъ менә шуңа күрә идея көрәшенең төп урынына әверелә дә. Моннан утыз еллар элек европалыларга бу хәлләр турында әйтсәң, ышанмаслар иде. Хәзер табигый итеп кабул ителә. Кешелекнең деградациясе куркыныч дәрәҗәгә җитеп килә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ОНЛАЙН ДАРУ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Могҗиза» бәясе

Арча районында яшәүче Зөлфия Вәлиеваның (исеме үзгәртелде) соңгы арада хастаханә юлыннан кайтып кергәне юк. Моннан ярты ел чамасы элек танылган бер блогердан детокс-программа алып эчкән булган ул.

– Балачактан бирле эчәклекләр белән проблема миндә. Гел дару эчеп, дәваланып яшим. Сторисларында бик мактый торгач, бер блогердан 6 мең сумга детокс-программа сатып алып эчеп карарга булдым. Башта файдасы булды кебек. Тынычлап ашый, эчә башладым, организм җиңеләйгәндәй булды. Әмма бер атна дигәндә, хәлем авырайды. Эч катты, сару кайнарга тотынды. Теге блогерга язгач: «Организм иярләнеп беткәнче генә шулай була ул, борчылма. Эчәклек шул рәвешле чистара», – диде. Бер курсны булса да алып бетерим инде, дип тагын теге даруларны эчә башладым. Икенче көнгә инде бөтен тәнем шешенеп чыкты. Шуннан теге блогер да сорауларыма җавап бирми башлады. Хәзер табибтан кайтып кергәнем юк. Аларны җаваплылыкка тартыйм дисәм дә, ерып чыга алмаячакмын. Аңа түгел, яшәргә дә хәлем юк. Үземдә дә гаеп бар, – ди Зөлфия.

Йөзен кыек булганга, көзгегә үпкәләмиләр дигәндәй, күпләр әнә шулай, үзем сатып алдым – үзем гаепле, ди дә бетерә, эшне зурга җибәрми. Шуңа да социаль челтәрләр аша халыкны «дәвалап» ятучы белгечләр сафы артканнан-арта бара бүген. Араларында фаш ителгәннәре бик сирәк.

Хәтерләсәгез, күптән түгел генә танылган социаль челтәрләр аша халыкны БАДлар ярдәмендә «дәвалаган» блогер Елена Корнилованы җаваплылыкка тарттылар. Аннан 13 мең сумга БАД сатып алган хатын аздан гына үлемнән калган. Катнашма составында никотин кислотасы нормадан 20 тапкыр (!) күбрәк булып чыккан. Тикшерә торгач, аның югары белем турындагы дипломнары да ялган икәне ачыкланган.

Мондый очраклар турында сөйли, кисәтә торалар. Аларга колак салучы гына аз. Яшерен-батырын түгел, хәзер күпләр кан китү, баш әйләнү кебек җитди билгеләр күзәтелгәндә дә, иң беренче эш итеп, төрле форумнарга, киңәш-табыш сәхифәләренә кереп, ярдәм сорарга ашыга. Газетабызның социаль челтәрләрдәге сәхифәсендә бу уңайдан махсус сораштыру уздырдык. Анда да фикерләр аерыла (рәсемдә. – **Д.Г.**).

– Сүзгә ышанып, могҗиза көтү бик җиңел. Миңа фәлән сум акча биреп, теге даруны сатып алыгыз да, берничә сәгатьтән инде аякка басачаксыз, дисәләр, кеше шуңа ышана. Белгечкә күренергә барсаң, тырышырга, ул кушканнарны төгәл үтәргә кирәк бит. Чын белгеч беркайчан да нәтиҗә өчен гарантия бирә алмый. Чөнки ул кешенең үзеннән тора, аның моңа ирешү өчен күпме көч куюына, әйткәннәрне төгәл үтәвенә дә бәйле. Шуңа күрә сезне тулысынча дәвалыйм, тиз арада аякка бастырам дигән сүзләргә шикләнеп карарга кирәк, – ди клиник психолог Эльмира Мияссарова.

Табиб алай эшләми

Халыкны онлайн рәвештә дәвалау белән шөгыльләнүче белгечләр нәрсәгә таянып эш итә? Бөтенләй башка юнәлештә эшләүче блогерлар үз сәхифәсендә дәвалану турында реклама урнаштырганда бу препарат, алымнарны алдан сынап карыймы? Бу сорауларыбыз һавада эленеп калды. Ник дигәндә, «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән онлайн «табиб»лар бу сорауларга җавап бирүдән баш тартты. Танылган блогерлар да юк-бар сәбәп табып, бу сораулардан качу ягын карады.

Ә менә халык белән турыдан-туры эшләүче тәҗрибәле табибларның бу уңайдан әйтер сүзләре шактый җыелган булып чыкты. Казан дәүләт медицина академиясенең госпиталь һәм хастаханә терапиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты, терапевт Регина Ахуновага социаль челтәрләр кушканча дәваланып, организмына зыян салган кешеләр белән еш эшләргә туры килә икән.

– Миңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләргә гел бер сүзне кабатлыйм. Интернетта авыруыгыз турында мәгълүмат эзләгәндә бик сак булыгыз, дим. Чирне бары тик табибыгыз язган дару һәм алымнар белән дәваларга кирәк. Нинди дер сорауларың булса, турыдан-туры табибка яки хастаханәгә барырга кирәк. Андый чакта интернет аша гына дәвалап ятучы «белгеч»кә мөрәҗәгать итү – зур хата. Әйе, анда соравыңа өйдән чыкмыйча гына тиз арада җавап алырга мөмкин. Әмма анда бирелгән киңәшнең ни дәрәҗәдә дөрес һәм нәтиҗәле булачагына беркем гарантия бирә алмый. Кешегә диагноз кую, аңа дәва билгеләү кебек эшләр онлайн рәвештә түгел, ә күзгә-күз очрашкач кына эшләнергә тиеш, – дип саный белгеч.

Күпкә китсә – агу

Без элемтәгә кергән табиблар соңгы арада социаль челтәрләрдә актив рәвештә рекламаланган, халыкта зур кызыксыну уяткан препарат һәм процедураларның чын асылын да ачып бирде. Әйтик, шул ук коллагенны гына алыйк. Ике блогерның берсе бүген халыкка әнә шул даруны сатарга тырыша. Ул һәркемгә файдалы, сәламәтлек белән бернинди проблемаң булмаса да, аны эчүнең зыяны юк, янәсе. Чаллының Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиб-травматологы Булат Закиров исә башка фикердә.



vk.com

Авырып китсәгез, социаль челтәрләрдәге киңәшләрдән файдаланасызмы?

Үзем белгәнне эшлим	46,41%
Юк, иң яхшысы – табибка күренү	31,37%
Әйе, иң беренче эш итеп шунда кереп карыйм	18,95%
Башта кем язганын тикшерәм	3,27%

«ВТ»ның «ВКонтакте»дагы төркемендә уздырылган сораштыру нәтиҗәсе

– Бер зыянсыз саналган коллагенны да табиб белән киңәшләшкәч кенә эчәргә ярый. Белер-белмәс кулланган очракта ул, киресенчә, сөякләрнең ныклыгын киметергә мөмкин. Рационны төрләндереп, дөрес тукланган очракта, сау-сәламәт кешегә тик торганда коллаген ашауның кирәге юк. Ул организмга ризык белән җитәрлек дәрәҗәдә керә. Желе, капсула, порошок формасындагы коллаген ит ашамаучы вегетарианнарга файдалы, – ди белгеч.

Табиб-терапевт, нефролог, диетолог Регина Ахуньянова соңгы арада популярлашып киткән витаминлы тамызгычлар (капельница) да сәламәтлек өчен зыянлы дип кисәтә. Система астында ятып, организмны берьюлы әллә ничә төрле витамин белән баетудан гыйбарәт ул. Табиб белән киңәшләшмичә генә шушы витаминлы тамызгычлардан файдаланучылар арасында кан басымы чамадан тыш күтәрелгән, хәтта микроинсульт кичергән кешеләр дә булган.

– Мондый система аша организмга натрий хлоридында эретелгән витаминнар керә. Шул ук вакытта аларга беркайда да теркәлмәгән, бернинди тикшерену узмаган законсыз матдәләр дә салына. Мисал өчен: тәндәге пигмент тапларын, җыерчыкларны бетерә дип саналган витаминлы тамызгыч составында С витамины, альфа-липоат кислотасы һәм глутатион дигән матдә бар. Соңгысы организмны тәмәке тартканда, кояш астында пешкәндә пәйда булган зарарлы матдәләрдән саклый. Ул организмда секунд саен бүленеп чыгып тора һәм яшь барган саен аның күләме кими. Аны бернинди дару, витаминлы системалар ярдәмендә дә арттырып булмый, – ди табиб. – Организмга система аша кертелгәндә глутатион эндотоксин бүлеп чыгара. Нәтиҗәдә кеше аңсызланып егылырга мөмкин. Альфа-липоат кислотасы исә шикәр чире китереп чыгара ала. Кешедә С витаминына кытлык булмаган килеш, организмга система аша шушы витамин кертелгән очракта кан китәргә мөмкин. Акча тозагы гына бу. Бер витаминлы тамызгыч уртача 3–5 мең сумга төшә. Санап карасаң, үзкыйммәте 300 сумга гына чыга. Мондый хезмәткә реклама ясар алдыннан блогерлар кат-кат уйлансын иде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«БАД эчеп кенә балага узып булмый»

Социаль челтәрләрдә сәламәтлеккә кагылышлы киңәшләр биргән кешеләргә ышаныргамы-юкмы? Бу сорау белән Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш репродуктологы **Фирая САБИРОВА**га мөрәҗәгать иттек.

– Социаль челтәрләрдә сәламәтлеккә бәйле киңәш биргән һәркем шарлатан дигән сүз түгел. Белеме, зур тәҗрибәсе булган күп кенә табиблар да биредә үз сәхифәсен алып бара. Әмма чын табиб беркайчан да социаль челтәрләр аша нинди дер дару, БАДлар эчәргә кушып утырмаячак. Онлайн рәвештә дәвалау, диагноз кую турында сүз дә була алмый. Чын табиб социаль челтәрдәге сәхифәсе аша, күп дигәндә, халыкны, үз сәламәтлегенә игътибарлы булып, вакытында табибка күренергә кирәклеген искәртә, үз тәҗрибәсендәге берәр үзенчәлекле очрак белән уртаклаша гына ала. Аның һәр сүзе, һәр посты: «Бу очракта иң элек табибка мөрәҗәгать итәргә киңәш итәм», – дип тәмамланырга тиеш, – ди белгеч.

– Шулай да халык андагы шикле белгечләргә сукырларча ышана бит.

– Кеше артык күп көч куймыйча гына максатына ирешергә тели. Дару эчәсең дә, тиз арада ябыгасың, мазь сылыйсың да, барлык чирләрдән котыласың, дип уйлый күпләр. Социаль челтәрләрдә ышаныч дигәнең язылучылар санына карап та билгеләнә бит. Язылучылары күбрәк булган саен сиңа киңәш биргән кеше дә тәҗрибәлерәк кебек тоела. Күпләр әнә шул сәбәпле дә ялгыша.

– Берара социаль челтәрләр аша, бала табарга ярдәм итә дип, махсус БАДлар да тәкъдим итә башлаганнар иде. Бу очракта алар ни дәрәҗәдә файдалы?

– Балага уза алмау социаль челтәрләр аша дәвалана торган чирләр түгел. Нинди дер препарат, БАД эчеп кенә могҗиза булмаячак! Дөрес, ышану көче дигән әйбер дә бар. Әгәр кеше фәлән әйберне эчкәч, сәламәтлеге яхшырасына, балага узачагына бик нык ышанса, ул шулай булырга мөмкин дә. Әмма бу кешенең психологик ныклыгына бәйле. Монда БАДларның бернинди катнашы да юк.

ФИКЕР

Роман АРХИПОВ, юрист:

– Социаль челтәрләр аша халыкны дәвалап яткан «белгеч» блогерлар 2011 елның 21 ноябрендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе гражданнарының сәламәтлеген саклау нигезләре турында»гы Законны боза. Махсус белеме һәм тәҗрибәсе булган табиб кына медицина ярдәме күрсәтә ала. Блогерлар, нигездә, реклама белән шөгыльләнә. Закон нигезендә, дару, БАДлар рекламалау тыела. Алар турында кайтавазлар урнаштыру да тыела. Моның өчен 2 мең сумнан алып 500 мең, сумга кадәр штраф яный. Әлеге препаратларны рекламалаган кешене җаваплылыкка тарту өчен, иң элек Татарстан Республикасы буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аннары медицина оешмасына барып, сәламәтлеккә нәкъ менә фәлән дару, БАД, хезмәт аркасында зыян салынганлыгын раслаучы белешмә алырга кирәк. Моннан тыш, нотариуска барып, сәламәтлеккә зыян китергән онлайн белгеч, блогерның социаль челтәрдәге сәхифәсен тикшереп, аның фәлән препарат сатуын, теге яки бу хезмәт күрсәтүен рәсми рәвештә теркәүләрен дә сорарга туры киләчәк. Бу хезмәт түләүле. Аннары алда телгә алган барлык белешмә, документлар белән полициягә барып гариза язарга кирәк. Анда җинаять эше кузгатудан баш тартсалар да, кулдагы документлар белән зыян салган «белгеч»тән компенсация түләттерергә мөмкин.

ЮГАЛМАСЫН МАЯ

ПЕНСИЯНЕ ЯШЬТӘН ҮК КАЙГЫРТЫРГА КУШАЛАР

Соңгы арада «Госуслуги.рф»дан килеп төшкән «сәлам хатлары» күпләрнең тынычлыгын качырды. Күпләрнең дип, 40 яшьтән узган хатын-кызларга һәм 45нең теге ягына чыккан ир-атларга булачак пенсияләрен исәпләп күрсәткәннәр. Юкка түгел бу! Әйтүләренә караганда, бүген ат урынына җигелеп эшләүче урта яшьтәгеләргә картлык көнен мөмкин кадәр иртәрәк кайгырта башларга кирәк. Пенсия акчасын «ВТ» хәбәрчесе дә исәпләп карады.

Агымдагы елдан башлап Россия Пенсия фонды халыкка картлык буенча иминият пенсиясенең якынча күләме, аның тупланма өлеше турында мәгълүмат җибәрә башлаган. «Сәлам хатлары» өч елга бер тапкыр 40–58 яшьлек хатын-кызларга һәм 45–63 яшьлек ир-атларга килеп торачак. Картаю турында уйлыйсы килмәсә дә, «күк»тән төшкән саннар белән Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинетта танышырга мөмкин. Шул рәвешле, түрәләр сүз белән булмаса, эш белән картлык көнен алдан ук кайгырта башларга ишарәли. Лаеклы ялда нәрсә көтәчәген белеп торыгыз, янәсе. Хатта пенсиягә кадәр тагын ничә ел стаж кирәклеге, картлык буенча акчаның якынча күләме, пенсиянең тупланма өлешендә күпме акча җыелуы турында мәгълүматлар бар. Пенсия исәпләргә керешкәнче, сүзгә баштан ук тотыныйк.

Пенсия ничек исәпләнә?

Дәүләт тарафыннан картлык буенча түләнә торган пенсия ике өлештән тора. Болар – пенсиянең иминият өлеше һәм тупланма өлеше. Әнә шул ике күрсәткечне кушасың да, булачак пенсияң килеп чыга. Акчаның иминиятләштерелгән өлеше рәсми рәвештә эшләгән елларда туплана. Шуңа күрә ул эш стажына һәм хезмәт хакы күләменә бәйле. Билгеле булганча, хезмәт хакының 22 проценты күләмендәге акча Пенсия фондына күчерелә. Алдан ук әйтик: бу акча айлык хезмәт хакыннан тотылмый. Ул эш бирүче оешма хисабыннан түләнә. 2002 елда пенсия системасына яңалык керде һәм Пенсия фондына күчерелгән акчаның бер өлеше (16 проценты) – иминият пенсиясенә, ә калганы (6 процент) тупланма пенсиягә китә башлады. Тик бу эш 2014 елда туктатылды. Пенсиянең тупланма өлеше «туңдырылган» дигән сүзләр әнә шуннан чыккан да инде. Дөреслектә, бу акча юкка да чыкмаган, «туңдырылмаган» да. Тупланма өлешкә хезмәт хакыннан акча «таммый», шул гына. Моңа кадәр җыелган акча исә әле дә хәрәкәттә. Тик бу хакта соңрак.

Иминиятләштерелгән пенсияне исәпләп карау өчен махсус формула гамәлдә. Тик хәзер сан «сугыштырып» җәфаланасы юк. Россия Пенсия фондының рәсми сайтында пенсия калькуляторы бар. Үз күрсәткечләреңне шунда кертәсең дә, компьютер булачак пенсияне шунда ук исәпләп бирә. Моңа бәйле кирәкле барлык мәгълүмат та – сайтта. Порталдагы шәхси кабинет аша шәхси счет турында сорау гына җибәрергә кирәк. Хат көнендә үк килә. Якынча пенсияне «ВТ»ның 37 яшьлек хәбәрчесе дә исәпләп карады. Әгәр быел пенсиягә чыгарга туры килсә, ай саен 14 мең 190 сум акча түләрләр иде. Аз, әлбәттә. Тик пенсиягә кадәр әле эшлисе дә эшлисе, шул гына күңелне тынычландыра. Нәрсәгә сөенергә дә белмәссең, билләһи!

> Икътисад белгече Илдус Сафиуллин сүзләренә караганда, хезмәт хакын «конверт»та алучылар яки рәсми рәвештә теркәлмичә генә эшләүчеләр киләчәктә ярык тагарак янында утырып калырга мөмкин. «Бүген яше 40тан узганнар арасында андыйлар бихисап. Ни эш стажлары, ни яхшы хезмәт хаклары юк. Пенсияләре дә булмаячак. Мондый очракта картлык буенча иминиятләштерү пенсиясе лаеклы ялга чыккач та биш елдан соң гына билгеләнә. Шуңа күрә «сәлам хатлары» җибәрүләрен хуплыйм. Бәлки, уйланырга бер сәбәп булыр. Алдан аяк киенгән откан», – ди ул.

Өч кешенең икесенә кирәкми

Әйткәнебезчә, 2014 елда илдә пенсиянең тупланма өлешенә мораторий кертелде. Гади тел белән әйткәндә, хезмәткәрләр өчен күчерелә торган акча алдагы кебек икегә бүленми. 22 процентның барысы да пенсиянең тупланма өлешенә китә. Узган атнада гына Россия Президенты Владимир Путин тупланма өлешне «туңдыру»ны 2025 елга кадәр озайтты.

Ә моңарчы тупланма өлештә җыелган акча ни хәлдә? Баксаң, яшенә күрә пенсия турында уйларга ашыкмаучыларның күбесен бу сорау, гомумән дә, борчымый икән. Быелның җәендә ил халкы арасында үткәрелгән сораштыруда катнашучыларның өчтән икесе пенсиянең тупланма өлеше кайда, күпме икәнен белмәвен әйткән. «Пенсия яше артты. Хәзер ул безгә кул җитмәс нәрсә булып тоела. Шуңа күрә пенсия акчасы турында уйлаганым да юк. Ничәдер ел элек өйгә килеп бик үгетләгәч, тупланма өлешне исеме дә онытылган бер банкка күчергән идем. Хәзер ул анда да түгел инде. Бер оешмадан икенчесенә күчеп йөри. Ел азагында «пенсиягезнең тупланма өлеше фәлән җирдә» дип хат җибәрәләр. Аның күләме турында да кызыксынганым юк. Ул акча без пенсия яшенә җиткәнче янып бетмәс дип кем ышандырып әйтә ала?» – ди башкаладагы сәүдә үзәкләренең берсендә эшләүче Гөлназ Фирдәрова.

Мәсьәләгә ачыклык кертүләрен сорап, Россия Пенсия фондының Татарстандагы идарәсе матбугат хезмәтенә мөрәҗәгать иттек:

– Тупланма өлеш «туңдырылмаган», мораторий гына гамәлдә. Ул моңарчы җыелган акчаны төрле фондларга күчерү мөмкинлегенә берничек тә комачау итми. Тупланма өлештә җыелган акчаны нишләтергә икәнен һәркем үзе хәл итә. Аны Пенсия фондында калдырырга яки дәүләтнеке булмаган пенсия бүлекләренә күчерергә ярый. Пенсия акчасыннан аермалы буларак, тупланма өлеш дәүләт тарафыннан индексацияләнми. Аннан керем генә алырга мөмкин.

> Элек тупланма өлешне пенсиягә чыккач кына алырга ярый иде. Хәзер мондый мөмкинлек 55 яшьтән узган хатын-кызларга һәм 60 яшь тулган ир-атларга бирелә. Дөрес, моның өчен картлык буенча пенсиягә чыккандагы кебек шартлар үтәлергә, ягъни эш стажы һәм пенсия баллары җитәрлек булырга тиеш. Ташламага ия гражданнар: Себердә эшләүчеләр, медицина хезмәткәрләре, тимер юлда эшләүчеләр, укытучылар кебек алдан пенсиягә чыгу хокукы булганнар тупланма өлешне тагын да иртәрәк ала башларга мөмкин.

Суммасына карап, тупланма өлеш берьюлы (әгәр җыелган акча иминият пенсиясенең 5 процентыннан да кимрәк икән, ул берьюлы бирелә. – **Ред.**) яки өлешләп түләнә. Ул ай саен пенсиягә өстәлеп киләчәк. Тупланма өлеш кеше үлгәннән соң да юкка чыкмый. Аны мирасчыларга түлиләр. Акчаны кеше вафат булганнан соң алты ай эчендә алырга кирәк, дип аңлаттылар идарәдә.

Тупланма өлеш турындагы мәгълүматны шәхси кабинет аша алырга мөмкин. «ВТ» хәбәрчесенең тупланма өлеше, мәсәлән, 15 елдан бирле колак ишетмәгән «Эволюция» дәүләтнеке булмаган Пенсия фондында булуы ачыкланды. Пенсия фонды белгечләре әйтүенчә, моңа әллә ни гаҗәпләнәсе юк. Бүген пенсиянең тупланма өлешенә бәйле алдалау очраклары шактый икән. Кайбер кибетләрдә товарны кредитка алганда пенсия акчасын дәүләтнеке булмаган Пенсия фондына күчерүне мәҗбүри шарт итеп куялар. Эш табарга ярдәм итә торган кадрлар агентлыклары да еш кына шундый таләпләр куя. «Алтын» пенсия вәгъдә итүчеләр ишек шакырга да мөмкин. Алдап булмаса, йолдап тупланма өлешне фәлән оешмага күчерергә үгетлиләр дә суга төшкәндәй юк булалар. Озын сүзнең кыскасы, документлар имзалаганда, шикле тәкъдимнәр булганда игътибарлы булырга киңәш ителә. Дәүләт Пенсия фонды хезмәткәрләре беркайчан да өйдән-өйгә йөрми, ди белгечләр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ФИКЕР

Эдуард ВАФИН, Россия Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге идарәчесе:

– Булачак пенсияне арттырам дип, пенсиянең тупланма өлешен ел саен бер фондтан икенчесенә күчерергә киңәш ителми. Моны бернинди югалтуларсыз биш елга бер тапкыр гына эшләргә ярый. Югыйсә инвестиция керемнәре исәпкә алынмый. Дәүләтнеке булмаган Пенсия фондын сайлаганда, иң элек аның эшчәнлеген тикшерергә кирәк. Аларның һәркайсының үз сайтлары бар. Фондның Иминиятләштерелгән затларның хокукларын гарантияләү системасына керү-кермәве дә мөһим. Бу нәрсә дигән сүз? Пенсиянең тупланма өлеше турында сөйләгәндә, гарантияләү системасы оешма ябылган очракта, дәүләтнеке булмаган Пенсия фондына күчерелгән тупланма өлешнең төп суммасын кире кайтару мөмкинлеген тәэмин итә. Ягъни фондка эшкә бирелгән акча югалмый. Ә менә инвестиция рәвешендә алган керем «яначак». Мәсәлән, эш бирүчегез фондка 10 мең сум акча күчергән ди. Әлеге акча 10 ел дәвамында әйләнештә булган һәм сез моннан 3 мең сум керем алгансыз. Оешма ябылган очракта, 10 мең сум акча югалмаячак. Бүген Иминиятләштерелгән затларның хокукларын гарантияләү системасына керүчеләр исемлегендә дәүләтнеке булмаган 28 Пенсия фонды бар. Ябылган очракта, лицензияләре алыну турында алар үзләре хәбәр итәргә тиеш. Алга таба тупланма өлеш Россия Пенсия фондына күчәчәк.

Пенсиянең тупланма өлешен ничек арттырырга мөмкин?

✓Дәүләтнеке булмаган Пенсия фонды белән килешү төзергә;
✓ана капиталын булачак пенсиягә салырга;
✓хезмәт хакыннан билгеле бер күләмдә акча күчереп барырга;
✓төрле финанслашу программаларында катнашырга.



Иминиятләштерелгән затларның хокукларын гарантияләү системасына кергән дәүләтнеке булмаган Пенсия фондлары

1. «Аквилон».
2. «Алмазная осень».
3. «Альянс».
4. «Атомфонд».
5. «Большой».
6. «Будущее».
7. «Волга-Капитал».
8. ВТБ Пенсия фонды.
9. «Газфонд» пенсия тупланмалары.
10. «Гефест».
11. «Доверие».
12. «Достойное будущее».
13. «Национальный».
14. «В.В.Ливанов исемендәге оборона-сәнәгать фонды».
15. «Открытие».
16. «Первый промышленный альянс».
17. «Профессиональный».
18. «Ростех».
19. «Сбербанк».
20. «Социум».
21. «Стройкомплекс».
22. «Сургутнефтегаз».
23. «Телеком-Союз».
24. «Транснефть».
25. «УГМК-Перспектива».
26. «Федерация».
27. Ханты-Манси дәүләтнеке булмаган Пенсия фонды.
28. «Эволюция».

16 декабрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Фәния Әхмәтҗанова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне (843) 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Кайда дөреслек?

Ноябрь ае өчен газга түләү квитанциясен китерделәр. Түләргә дип барсам, газны яңа тариф белән исәпләгәннәр. Бәяләр 1 декабрьдән генә артты түгелме? Зинһар, ачыклык кертегез.

Мөнир ФӘРДИЕВ.
Нурлат районы Колбай-Мораса авылы

«Нурлатгаз» оешмасының абунәчеләр бүлеге җитәкчесе Татьяна Смирнова:
– Безгә Мөнир Фәрдиевнең шәхси документлары кирәк. Без аның газ счетчигының мәгълүматларын кайчан биргәнен дә үзеннән башка карый алмыйбыз. Монда ачыклык кертергә кирәк. Ул безгә 2-14-05 номеры буенча шалтыратсын иде. Мин татарча аңламыйм, әмма бүлектә татар кызлары бар. Алар Мөнир абыйга барысын да аңлатып бирер.

Җырчыларга ник сүз әйтмиләр?

Чаллыбызда көн саен диярлек татар эстрадасы артистлары килеп концерт куя. Күбесе 800 урынлы залда утырган тамашачыны алдап, фонограммага җырлап китә. Мин Филүс Каһиров, Ришат Төхвәтуллин турында әйтмим. Әмма арада авыз селкетеп кенә торучылары да бар бит. Бу җырчылар халыкны алдалый булып чыга түгелме? Элек Кашпировский телевизор алдына бер чүмеч су куйдырып, кеше алдый иде. Болар да шуның төсле дип уйлыйм мин.

Фәрдия ГАЛИМҖАНОВА.
Чаллы

Рөстәм Закиров, Татарстанның халык артисты:
– Мин Фәрдия ханым белән килешәм. Халык алдына чыгып, үз тавышың белән җырламауны оятсызлыкка саныйм. Фонограммага каршы бернинди закон да юк. 10–15 еллар элек аны тыймакчы булганнар иде. Әмма фонограмма булмагач, съемка начар була дип, тагын шуңа әйләнеп кайттылар. Үземнең халыкны алдаганым юк.

Зөфәр Хәйретдинов, Россия авторлар җәмгыятенең Татарстандагы бүлеге җитәкчесе, композитор, Татарстанның халык артисты:
– Фонограмма кулланунының төрле сәбәпләре бар. Беренчесе – җырчы көн саен концерт куя. Әмма кайчак аның тавышы тиешле дәрәҗәдә булмаска мөмкин. Бу очракта кулланучылар бар. Ә менә кайбер җырчылар бөтенләй җырлый белми. Студиягә барып, яхшы итеп тавыш яздырып кайта да, шуны җырлаган булып йөри. Андыйларның күбесенең белеме дә юк. Алар гомерләрендә дә «тере тавыш»ка җырлый алмый. Телевидениедә концерт төшерү дигән әйбер бар. Ул фондта кала. Анда хата китәргә тиеш түгел. Ул җырларны кабат-кабат төзәтеп булмый. Бу вакытта фонограмма куела. Андый җирләрдә һәр артист өчен микрофон да көйләнми.

Законга килгәндә, андый таләп юк. Җырчыларны бернишләтеп тә булмый. Ни дисәң дә, яздырылганы да аның тавышы бит инде. Әмма бер шарт бар – җырчы концертында фонограмма куллана икән, ул бу хакта алдан кисәтеп, белдерүгә язарга тиеш. Мондый концертның бәясе дә түбәнрәк куела. Тик берәү дә белдерүенә фонограмма хакында язмый да, язмаячак та.

Нишләп акчасын бирмиләр?

Үземә кирәкле аяк киемен элек районның Социаль иминият фондыннан барып ала идем. Баксаң, хәзер аны электрон сертификатсыз бирмиләр икән. Авыл кешесе ул сертификат турында каян белсен соң? Акчабызны түләп алыр идек, кыйммәт тора. Без, инвалидлар, аны дәүләттән бушка алырга тиеш бит. Каян килеп чыкты ул сертификат дигән нәрсә?

Рамил ШӘФЫЙКОВ.
Арча районы

Россия Социаль иминият фондының Татарстандагы бүлеге матбугат хезмәте җитәкчесе Марина Власова:
– 2021 ел ахырында физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр үзләренә тиешле тернәкләндерү чараларын электрон сертификат белән ала башлады. Әлеге сертификат электрон рәвештә теркәлә һәм «МИР» картасына беркетелә. Үзләренең махсус тернәкләндерү программалары (ИПР) булган кешеләр электрон сертификаттан файдаланырга хокуклы. Аны Дәүләт хезмәтләр порталы, безнең районнарда урнашкан бүлекләр аша алырга була. Моның өчен сезгә гариза язарга һәм картагызның реквизитларын алып килергә кирәк. Аннары Социаль иминият фонды һәркемгә тиешле акчаны картага күчерә. Тернәкләндерү чараларын сатып алыр өчен, безнең сайтка кереп, «Каталог технических средств реабилитации» дигән бүлекне табып, үзегезгә тиешле товарны сайлый аласыз. Үз акчагызга алган очракта аның өчен компенсация кайтарып була. Тулырак мәгълүматны Социаль иминият фонды бүлекчәләреннән дә белергә мөмкин.

Мәчетне ничек рәсмиләштерәсе?

Безнең авылдагы мәчетне рәсмиләштерә алмыйлар. Муллабыз ике ел буе документлар белән йөри инде. Авылдагы мәчетләрне элек теркәп тормаганнар бит инде. Халык акча җыйган да мәчетне салып куйганнар. Хәзер менә авылдагы мәчетләрне исәпкә куясы икән. Ни өчен муллага ярдәм итмиләр? Бу процессны ничек тизләтеп була? Шуны аңлатсагыз иде.

Нәҗия МИНХӘЕРОВА.
Әлмәт районы Елховой авылы

Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте җитәкчесе Резеда Закирова:
– Безнең «Вакф» дигән фондыбыз бар. Алар биналарны теркәүдә ярдәм итәләр. Шунда мөрәҗәгать итсеннәр. Телефоннары: 8 (843) 598-01-00.

Кайчан түлик?

Без гаиләбез белән салым түләргә онытканбыз. Элеккеге төсле почтадан хат килми икән хәзер. Дәүләт хезмәтләре порталында беребез дә теркәлмәгән. Үзебез яшәгән салым инспекциясенә барып сорарга да башка килмәгән. Хәзер ул салымны түлисеме? Әллә инде икенче елда икесен бергә түләсәң дә ярыймы?

Ләйсән ШӘРИПОВА.
Казан

Казан шәһәренең 6 нчы салым инспекциясенең өлкән белгече Рәмзия Мөхетдинова:
– Салымны түләргә кирәк. Әгәр аны 1 декабрьгә хәтле түләмәгән булсагыз, икенче елны көтеп торырга кирәкми. Һәр түләнмәгән көн өчен пеня өстәлеп бара. Әгәр кеше өч ай эчендә дә салымын түләми икән, без аңа хат җибәрәбез. Аннан соң да түләмәсә, карар чыгарып, эшне суд приставларына тапшырабыз.

Хат ташучы табылырмы?

Зәй районының Апач (Сармаш-по Ирне) авылында хат ташучы юк. Ярты ел тилмерәбез инде. Ул авылда элек хат ташучы бар иде, әйбәт кенә эшләп тә йөрде. Тик нindидер сәбәп белән аны эштән җибәрделәр. Авылда өлкәннәр күп. Аларга хат ташучы бик кирәк. Элеккегесе барлык түләү эшләрен санап, аңлатып бирә иде. Авылда кибет тә булмагач, кирәкле товар белән тәэмин итеп торды. Иң мөһиме, бөтен кеше белән уртак тел табар иде. Әлегә ул эшләми. Чакырсалар, бәлки, кире дә кайтыр.

Бер төркем әбиләр

Бохарай авылы җирлеге хезмәткәре:
– Без бу проблеманы беләбез. Элеккеге хат ташучы эштән үзе киткән иде. Хәзергә вакытта аның белән яңадан сөйләшүләр бара. Кире эшкә чыгуын сорыйбыз. Әлеге мәсьәлә хәл ителер дип көтәбез.

Зәй районының почта бүлеге җитәкчесе Ирина Карпова:
– Хәзерге вакытта бу авылга почта мөдире хезмәт күрсәтә. Эштән киткән хат ташучы белән сөйләштек. Аны хезмәт хакы канәгатьләндерми. Ә акчаның артуы көтелми. Үзебезнең хезмәт хакы өстәү мөмкинлегебез юк.

Тукталышларны кем куя аны?

Казанның Совет районында яшәүче туганнарыма барган идем. Автобусны озак көтәргә туры килде. Ул көнне карлы яңгыр яуды. Тукталышка кереп торырлык түгел. Алар бит хәзер башкача ясала икән: артына тишекле тимер калай беркетеп. Бер җире дә капланмаган. Кеше кар яуса да, яңгыр яуса да, салкында торырга тиеш булып чыга. Ул тукталышны кешегә яхшы булсын дип ясарга ярамый микәнни соң? Шуны беләсе килә иде. Тагын бер үтенечем бар: кайбер тукталышларда автобус килүен күрсәтүче таблолар юк. Карбышев урамына кайчан куярлар икән? Аларны нинди тәртип буенча урнаштыралар?

Рәзинә СӘЕТГӘРӘЕВА.
Казан

Казан мэриясенең матбугат үзәге:
– Тукталышларны яңарту буенча аерым программа юк. Аны я юлны төзекләндерүчеләр ясап куя, я инде реклама бирергә теләүче фирма эшли. Сез әйткән адрес буенча тукталышның нинди халәттә икәнен ачыкларбыз.

Казан шәһәренең Транспорт комитеты:
– Казанда җәмәгать транспорты тукталышларын электрон мәгълүмат таблолары белән тәэмин итү тиешле акча бүленгән саен этаплап башкарыла. Карбышев тукталышы – исемлекнең башында. Әмма әлегә финанслау каралмаган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәхмәт ишетү рәхәт

Күптән түгел «Идел» тернәкләндерү үзәгендә ял итеп кайттым. Аннан күңелемдә рәхәт хисләр калды. Мин анда килүгә үк баш табиб Александр Камаевка: «Миңа дигән ризыкны хәләл итә алмыйсызмы?» – дигән идем. Ул шул арада пешекчене чакырып та китерде, хәләл ризык әзерләргә кушты. Пешекче Марианнаниләр генә пешереп ашатмады. Баш табиб сәркатибе Наталья көн саен хәлләремне сорашып торды. Сезнең газета аша тернәкләндерү йорты җитәкчелегенә, үземне дәвалаган бүлек мөдире Ирина Гончаровага, администратор Гүзәлгә, анда эшләүчеләрнең барысына да рәхмәтемне җиткерәм.

Райлә ФАТЫЙХ

***

Моннан берничә ел элек «Ватаным Татарстан» газетасына ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән идем. Ул вакытта журналист Гөлгенә Шиһапова безнең проблема турында газетада да язып чыкты. Төп борчуым бакчабыз аша узган электр баганаларын алдыру иде. Без моны үз көчебез белән генә башкарып чыга алмас идек. «ВТ» журналисты безне изге күңелле кеше белән таныштырды. Аллага шөкер, шатлыгыбыз эчебезгә сыймый. Шул ут баганаларын алдылар. Мең рәхмәт сезгә!

ЗӨЛФИДӘ апагыз. Әтнә

12 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Рыцари вечности». Шигабутдин Марджани 12+
00.05 «Фолиант в столетнем переплете». Редкое турецкое издание всемирного атласа 12+
00.20 «Таяну ноктасы» 16+
00.45 «Ватандашлар» 12+
01.10 «Кәмит Җәвит» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-22» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.25, 17.20, 21.55 Новости
06.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.20, 14.30, 01.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
16.35, 21.20 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.25 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Торпедо» (Нижегородская область) – «Новая генерация» (Сыктывкар). Прямая трансляция
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
22.30 Смешанные единоборства. UFC. Магомед Анкалаев против Яна Блаховича. Трансляция из США 16+
00.05 «Один на один» 12+
00.45 «Один день в Катаре» 16+
03.15 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Феникс» (Китай) 0+
04.40 «Территория спорта» 12+
05.05 «Спортивный детектив. «Мёртвая вода» для ЦСКА» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10, 00.00 Никита Панфилов. «ПЁС» (S) 16+
01.00 Боевик «ДВЕНАДЦАТЬ ЧАСОВ» (S) 16+
02.40 Сериал «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
10.30 «Шаг в карьеру» 16+
10.35 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Медуза» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «Кризисный центр» 16+
19.00 «МАМА». 1-я – 4-я серии 16+
23.00 «Порча». «Ночной кошмар». «Прищепка» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.05 «ЩИТ И МЕЧ». «БЕЗ ПРАВА БЫТЬ СОБОЙ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «АЛЕКСАНДРОВСКИЙ САД». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Холодная война. Битва экономик». Док. сериал. 1-я серия. Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «Хранители времени». Док. фильм. Премьера! 16+
01.40 «ССОРА В ЛУКАШАХ» 12+
03.25 «АЛЕКСАНДРОВСКИЙ САД» 16+

13 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Соотечественники» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Малика Гельмутдинова. Доброта, спасающая мир 12+
00.45 «Рыцари вечности». Каюм Насыри 12+
01.00 «Фолиант в столетнем переплете». К 1100-летию принятия ислама 12+
01.10 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал премьерасы 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30 «Татар халык җырлары» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-22» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Гарнова, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.25, 20.45 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.20, 14.30, 18.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
16.35, 20.50 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
20.25 «Один на один» 12+
21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/2 финала. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
01.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/2 финала. Трансляция из Катара 0+
03.15 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Самара» 0+
05.05 «Спортивный детектив. Шахматная война» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10, 00.00 «ПЁС» (S) 16+
00.50 «Основано на реальных событиях» 16+
02.15 Сериал «ЗАЩИТА КРАСИНА» 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
10.30 «Шаг в карьеру» 16+
10.35 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Ракушка» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «МАМА». 5-я – 8-я серии 16+
23.00 «Порча». «Петля смерти». «Покойник» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «АЛЕКСАНДРОВСКИЙ САД». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ЩИТ И МЕЧ». «ПРИКАЗАНО ВЫЖИТЬ...» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «АЛЕКСАНДРОВСКИЙ САД». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Холодная война. Битва экономик». Док. сериал. 2-я серия. Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
01.30 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
02.55 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.30 «АЛЕКСАНДРОВСКИЙ САД». 5-я и 6-я серии 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 12–18 ДЕКАБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Җиң сызганып эшләргә әзер торыгыз: еленке-салынкылыктан котылырга вакыт. Ел ахыры бит... Өегездә юк-бардан бәхәс чыкмагае. Юл куегыз – соңыннан сөенеп бетә алмаячаксыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Тормышыгызга югарыдан карап алу теләге туар. Бу үзегездә сөю-сөелү, кызгану хисләре җитеп бетмәвен аңлауга китерер. Көтмәгәндә килеп кергән бер яхшы хәбәр башыгызны әйләндереп җибәрер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бер мәсьәләдә бераз сабыр итәргә туры килер. Барысын да вакытында һәм дөрес эшли алуыгыз күңелегезгә зур канәгатьлек хисе китерер. Күптәнге хыялларыгыз тормышка ашар, саллы гына керем керер.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Үтә отышлы тәкъдимнәр бер-бер артлы ява башлар. Үзегезне дә алдатмас, башкаларны да үпкәләтмәс өчен байтак кына баш ватарга туры килер. Атна ахырында көтелмәгән бер очрашу күңелегезне алгысытып җибәрер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Үзегез өчен гадәти булмаганрак эшләр белән мәш килергә кирәк булыр. Хезмәттәшләрегезнең киңәше ярап куяр. Якыннарыгыз арасыннан берсе шәп хәбәр белән куандырыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Атнаның беренче яртысы эштә дә, өйдә дә салмак, тыныч узар. Әз-мәз генә тавыш-мазар чыкса, үзеннән-үзе сүрелер. Ә менә икенче яртысында шактый ук дулкынланырга туры килер. Әле ярый, барысы да әйбәт бетәр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Эштә катырак сүз әйткәнче, кат-кат уйлый күрегез. Юкса кара тавыш чыгарырга мөмкинсез. Шәхси тормышыгызда муллык шайләнер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Үзегезне бик акыллы кеше итеп тою мөмкинлеге чыгар. Хәтта борыннарын чөеп йөргүче кемсәләр дә булдыклылыгызны күреп сокланырга мәҗбүр булыр. Гомумән, эштә дә, тормышта да гел уңай килеп торыр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Төрледән-төрле мөмкинлекләр чоры. Әмма ашыкмаска кирәк. Эшегез күп вакытыгыз һәм көчегезне алса да, үзегезне гаҗәеп дәрәҗәдә бәхетле кеше итеп тоярсыз.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Нindидер яхшы үзгәрешләр телиме күңел? Ел ахырындагы мөһим эшләрегезнең очына чыгуга, аларны күреп сөенәчәксез! Хезмәттәшегез авызыннан чыккан сүзләр үзегезне рәхәт уйга салыр.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Карьера баскычыннан ыргылып менеп китү өчен бик шәп мөмкинлек пәйда булыр. Аны кулдан ычкындырмассыз бугай. Дөреслек ягында булуыгыз да моңа ярдәм итәр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Дәгъва-мазар белдерә күрмәгез: якыннарыгызны үпкәләтүегез бар. Көндәлек эшләрне онытмагыз, кокса шелтә алуыгыз ихтимал. Дусларыгыздан шатлыклы хәбәрләр көтегез. Сәламәтлегегезне кайгыртыгыз.

ТӨЗ УТЫР, ЯХШЫ УТЫР!

Арканың иң зәгыйфь өлеше. Табиблар билне шулай дип атый. Көндәлек тормышыбызда еш кына бөтен авырлык нәкъ менә шуңа төшә. Шуңа аның ара-тирә авыртып алуына дә әллә ни исебез китми. Мазь сылыйбыз да – вәссәлам! Табиблар исә бил авырту җитди чир билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә.

Бил авыртуның нечкәлекләре, аны кисәтү кагыйдәләре турында Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина ГАЛИУЛЛИНА сөйләде.

:: Бил ни сәбәпле авыртырга мөмкин?

– Көндәлек тормышыбызда бөтен авырлык билгә төшә. Авыр әйбер күтәргәндә генә түгел, җәяү йөргәндә, утырганда да авырлык килә аңа. Аркабыздагы иң зәгыйфь урын да шул. Бил бөерләрдә хилафлык булганда, сидек юлы, эчәклек авырулары вакытында да борчырга мөмкин.

:: Бил авыртканда иң элек нәрсәгә игътибар итәргә?

– Кисәк кенә авырта башлап, гел борчып торса, сузарга ярамый. Бил авырту утракса нервы кысылу, остеохондроз, радикулит, умыртка арасындагы бүсер, бил мускуллары ялкынсыну турында кисәтергә мөмкин. Ул зиһен таралу (рассеянный склероз), остеопороз билгесе дә була ала. Бил авыртканда аны үзлегеңнән генә дәваларга маташу – зур хата. Бу очракта кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә, иң беренче чиратта терапевт белән неврологка күренергә кирәк.

:: Бил авыртканда җылыта торган мазьлар сөртергә ярамый, ул яман шеш китереп чыгарырга мөмкин, диләр. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?



БИЛ АВЫРТУНЫ КИСӘТҮ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

➤Гәүдәне төз тотыгыз. Утырып эшләгәндә дөрес итеп утырырга онытмагыз. Тезләр оча-бот буыннарыннан бераз өстәрәк торсын. Моның өчен тәбәнәгрәк урындыкта утырырга яки аяк астына бераз биегрәк әйбер куярга кирәк. Урындык белән арка арасына мендәр куйсагыз да яхшы.

➤Озак вакыт утырырга туры килгәндә, торып, бераз хәрәкәтләнеп, билне, арканы ял иттереп алырга да онытмагыз.

➤Ортопедик матраста йоклау да бил авыртуын кисәтергә ярдәм итә. Ул сыгылмалы һәм шактый каты булырга тиеш.

➤Авыр әйбер күтәргәндә аякларны бераз бөгеп, аннары тураерга кирәк. Бу очракта төп авырлык билгә түгел, ә аякларга төшәчәк.

➤Авыр әйбер күтәргәндә, ике кулга да авырлык тигез күләмдә төшәрлек итеп тотарга кирәк.

➤Даими рәвештә корсак һәм арка мускулларын ныгытучы күнегүләр ясасагыз да файдалы булачак.

– Бил авыртканда аны, дөрестән дә, җылытырга ярамый. Ник дигәндә, җылылык тәэсирендә нерв җепселләре тагын да катырак ялкынсыначак. Бу исә бил авырту да көчәячәк дигән сүз. Сызлаган урынны җылыткач, бил авырту яман шешкә әверелә дигән сүзләр дөреслеккә туры килми. Һәрхәлдә, бу уңайдан беренди фәнни аңлатма да юк. Ә менә бил авырту үзе яман шеш билгесе була ала. Минем тәҗрибәмдә шундый бер очрак булды. Бер ир-ат биле нык авыртудан зарланып мөрәҗәгать итте. Остеохондроз дип уйлап, билне үзлегеннән генә дәвалап маташкан ул. Тикшеренә торгач, анда яман шеш икәнлеге ачыкланды. Биле дә шуңа борчыган.

:: Бил авырту коронавируснең да билгесе була аламы?

– Ковид булганда башка билгеләр күзәтелә. Тән температурасы күтәрелә, ютәл пәйда була, кеше ис һәм тәм сизми башлый. Әмма көчле хәлсезлек, организмның агулануы аркасында коронавирус йоктырган кешенең биле дә авыртырга мөмкин.

Һәр өйдә булырга тиешле дарулар

Саклап куй!

✓Бинт, мамык, марлядан салфеткалар.
✓Градусник, тонометр, нашатырь спирты, жгут.
✓Медицина һәм бактерицидлы пластырь.
✓Кайчы, пинцет, җылыткыч (грелка), улчи торган стакан, пипчәткә, битлек.
✓Җәрәхәтләрне йогышсызландыра һәм яраларны төзәтә торган чаралар: пантенол, 3 процентлы водород перекисе, мирамистин, йод, хлоргексидин, зелёнка.
✓Авыртуны баса һәм температураны төшерә торган препаратлар: ибупрофен, парацетамол, но-шпа (дротаверин, папаверин).
✓Буыннар авыртканнан мазьлар.
✓Аллергиягә каршы: лоратадин.
✓Йөрәк авыртканнан: нитроглицерин.
✓Агулану очраклары була калса: полисорб, смекта, регидрон.
✓Эч йомшарта торган: лактулоза (дюфалак). Эч катканнан ашыгыч ярдәм сыйфатында клизма ясау өчен микролакс.
✓Югары кан басымын төшерә торган: каптоприл.
✓Салкын тигәннән: борын юдырта торган эремәләр, кан тамырларын кыса торган борынга тамызу өчен тамчылар (називин), тамак авыртканнан суыра торган кәнфитләр (холлс, стрепсилс).
✓Даруларны караңгы салкынча һәм балалар тимәслек урында саклагыз. Яраклылык вакыты чыкканнарын ыргытып һәм яңаларын өстәп торыгыз.

Белеп тор!

Үзе тәмле, үзе шифалы

БӨЕРДӘГЕ ТАШЛАРДАН

Кабак суы бөерләрдән вак таш, комнарны чыгара. Бу фәнни яктан дәлилләнгән. Кабак суы ялкынсынуны киметү, сусауны басу, тынычландыру һәм бәвел кудыру үзлегенә дә ия. Бәвел буленүдә тоткарлыклар булганда да табиблар кабак суы эчәргә киңәш итә.

БАБАСЫРНЫ БЕТЕРҮ ӨЧЕН

Киптереп чистартылган 300 г кабак төшен яхшылап изегез, бал яисә кайнатма өстәгез. Бу катнашманы акрын гына (1 сәгать дәвамында) ач карынга ашагыз.

ҮТ КУЫГЫ ЯЛКЫНСЫНГАННАН

Үт куыгы һәм бавыр ялкынсынулары вакытында «кабак сөте» эчү файдалы. Аны җиңел генә әзерләргә була. 50 г чистартылган төшкә су (80 мл) һәм шикәр комы (20 г) салып изегез. Аннары файдалы «сөт»не ач карынга эчегез.

БАВЫР БОРЧЫГАННАН

Авыру бавырга кабак орлыклары төнәтмәсе дә ярдәм итәр. 250–500 г орлыкка 0,5–1 л кайнар су салып, 2 сәгать төнәтегез. Төнәтмәне 1 сәгать дәвамында эчегез.

ҮТ КУДЫРУ ӨЧЕН

Кабак йомшагын турап, тары боткасы пешерегез. Боткага май, сөт, бал өстәгез. Мондый ботканы һәр көнне ашагыз. Үт куыгы авырулары вакытында аның файдасы инде күптән сыналган.

Үзем сынадым

Көзән җыерудан коткарды

Аякны көзән җыерганда, балан кайрысыннан ясалган төнәтмә булыша икән. Аны әзерләү өчен 4 чәй кашыгы кипкән һәм вакланган кайрыга 200 мл су салып, 30 минут кайнатасы. Аннары шуны сөзеп, кимегән кадәр су өстисе дә көненә 3 мәртәбә ашар алдыннан 1әр аш кашыгы эчәсе.

Зөлфия САБИРОВА. Арча

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина
СЕМЕНОВА

ҮЗЕ ЮА, ҮЗЕ СЕБЕРӘ

Тузан суырткыч-роботны ничек сайларга?

:: Уенын-чынын бергә кушып дигәндәй, Яңа елга Кыш бабайдан үземә робот-полотер бүләк итүен сорыйсы килә. Ниндиен сайласам әйбәтрәк булыр икән?

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА.
Казан

vk.com

Чыннан да, хәзер байтагыбыз тузан суырткыч-робот, идән сөрткеч-робот кебек ярдәмчеләрне бик тә үз итә башлады. Кайсына өстенлек бирергә икәнен һәм бер-берсеннән ничегрәк аерылып торуларын электроника кибете консультанты Марат Хисамиев аңлатты.

Исеменнән үк аңлашылганча, полотер шома идәнне (ламинат, линолеум җәелгән) сулы чүпрәк белән сөртеп чыгара. Шулай ук аны тузан җыю өчен генә дә көйләргә була. Әйе-әйе, мондый робот тузан-пычракны суырмый, бәлки җыя гына. Ягъни артык пычрак булмаган идәнне генә әйбәт чистарта ул. Билгеле бер сәгате җиткәч (аны үзеңә ничек кирәк, шулай куясың), «оясы»ннан (зарядка җыю урыны) чыгып, эшли башлый. Эшен тәмамлагач, кире кереп утыра. Шул рәвешле атна буе эшләткәннән соң, хуҗабикәгә (хуҗага булса да ярый) роботның тузан җыю өчен билгеләнгән савытын бушатасы гына кала. Ә менә келәмгә килгәндә, бигрәк тә озынрак йонлысын чистартуга «теше үтми», ди консультант.

Икенең берсе

Марат аңлатып үткәнчә, полотер ике төрле була. Беренчесе – төбенә идән сөртү өчен микрофибрадан салфетка урнаштырыла торганы. Мондый робот тузанны юеш чүпрәк белән сөртә, ләкин нык басып юа алмавы сәбәпле, катырак пычракны бетерә алмый. Икенчесе – әйләнеп торган щеткалысы яки роликлысы. Монысы исә идәнне чүпрәккә караганда әйбәтрәк, басыбрак юа. Пычрак идәнне чистарту-җыештыру өчен, әлбәттә, монысы уңайлы.

Шул ук вакытта гадәти тузан суырткыч-роботларның да идән юуга сәләтләләре бар икән. Болары «для влажной уборки» дип атала. Эш рәвеше болайрак. Башта тузан суырта. Аннан идәнне юа. Соңгысына автомат рәвештә яки хуҗабикә микрофибрадан ясалган чүпрәкне юешләткәннән соң керешә. Әлбәттә, автомат эшләүчесе кыйммәтрәк тора.

Маратның укучыбызга тәп киңәшләре болайрак. Идән юуны артык мәшәкатькә санамаучы хуҗабикәләргә роботның гадәти тузан суырта торганы гына да бик әйбәт. Бөтен тузан-пычракны, келәмне дә менә дигән итеп чистарта ул. Полотер, бигрәк тә щеткалысы, идән юарга яратмаучылар өчен кулай. Ләкин иң яхшысы – юешләтмичә дә, юешләтеп тә җыештыручы робот (робот с сухой и влажной уборкой).

Белсәң, зыян итмәс

МАНДАРИН МӘРҖӘННӘРЕ

Чыршы бизәп куярга вакыт. Бәйрәм күркенә мандариннан ясалган мәрҗәннәрне дә элеп куйсакмы! Аның исе балачактагы Яңа елларны искә төшерәчәк.

Цитрусны ничек итеп җепкә тезәсең, согы агып, бөтен җирне пычратачак бит, дип уйларга ашыкмагыз. Сере бар. Табигый мәрҗән ясау өчен ваграк мандариннар, камыт энәсе һәм органзадан ясалган үтә күренмәле юка тасма (тәрәзә челтәреннән калдык-постык һәркемдә бар) кирәк. Җимешләрне камыт энәсе белән үтәли тишәләр һәм, 2–3 см ара калдырып, тасмага тезәләр. Сок тамчылары агып чыкса да, үтә күренмәле тасмада таплар күренмәячәк. Тасмага тезелгән мандариннарны, согы органзага сеңеп, кипсен өчен, төнгә өстәлдә калдыралар. Икенче көнне мәрҗәнне инде согы агудан курыкмыйча чыршыга элеп куярга мөмкин.

Чыршыдагы мандарин мәрҗәне гыйнвар ахырына кадәр бүлмәгә хуш ис таратып торачак!

Аш-су

Бәйрәм табынына – «Идеал» казы

Резедә Садыйкова рецепты

Каз түшкәсе идеаль дәрәҗәдә тәмле булып пешсен өчен, аны алдан әзерләп куярга кирәк. Башта түшкәне зур кәстрүлгә салып, тозлы суда 1,5 сәгать чамасы пешерәбез. Пешкәч, суыткырга алып куябыз.

100 мл соя соусы, 3–4 аш кашыгы майонез, бераз тоз, борыч, тәмләткечләр салып, катнашма әзерлибез. Түшкәнең эчен-тышына шуны сылап, берничә сәгатькә (ә иң яхшысы – бер тәүлеккә) суыткычта калдырабыз. Эчлеге җимешләрдән торачак. Түшкә эченә ике-өч алма, әфлисунны, кабыгы белән бергә зуррак кисәкләргә турап, бераз гына виноград, теләсә нинди чикләвек (50 г чамасы) тутырабыз. Аерылып китмәсен өчен теш чистарткыч таякчыклар белән эләктереп куябыз. Казны газ мичендә куеп, башта 100 градуслы температурада –

40 минут, аннан соң температураны 180 градуска җиткереп, тагын 40 минут кыздырып алабыз. Казны әледән-әле астын-өскә әйләндереп, бүленеп чыккан согы белән коендырып торабыз.

Ризыкны табынга, яшел тәмләткечләр һәм яшелчә белән, суык килеш тә, кайнар килеш тә куярга мөмкин.

Укучы хаты

ЯҢА ТУФЛИ АЯКНЫ КЫСА

Гадәттә мин үзем кибеттән алып кайтуга ук яңа туфлиның эчке ягын спирт эремәсендә чылатылган мамык белән юешләтәм. Аннан соң юкарак оекбаш белән киеп, өйдә бер-ике сәгатьләп йөрим. Шушы вакыт эчендә аяк туфлига ияләшә, шуңа күрә кысудан, авырттырудан туктый. Тагын бер әйбәт ысул – суыткычта туңдыру. Монысы замша һәм нубуктан эшләнгән аяк киеме өчен кулай. Туфли эченә сулы пакет урнаштырам да, суы катканчы, 4–6 сәгать суыту камерасында тотам. Су каткач, күләме арта, шулай ук аяк киеме дә зурая.

Табигый күннән эшләнгән туфли аякны кысра, серкәгә спирт кушып (1:1 нисбәтендә), кыра торган өлешен шуның белән чылатам. Оекбаш киеп, берәр сәгать чамасы йөрим.

Тукыма аяк киеме өчен ак кәгазь кулланам. Аны кисәкләргә ертып, җылы суга салып чылатам һәм туфли эченә тыгызлап тутырам.

«Туфли-«лодочка» таррак булган очракта, өйдән чыкканда, аяк бармакларына гадәти пластырь ябыштырам. Кырмый да, йөрергә дә уңайлы.

Инде килеп, яңа аяк киеменең табанын, шома идәндә шумасын өчен (офис яки кибет идәне шулайрак була), наждак кәгазе белән ышкып алам.

Гөлчәчәк ХӘЙРУЛЛИНА.
Апас районы



1



2



3

4

Җылы бүләк

Кул эше

Яңа елга якыннарыгызга башмак бәйләп бүләк итәргә мөмкин. Үз кулыгыз белән эшләнгәч, кадерлерәк тә булачак әле ул. Аны бер кичтә әзерләп куярга була!

39 нчы үлчәмле бер пар башмак бәйләү өчен 100 грамм (230 м) йон җеп, 3 нче номерлы оекбаш энәләре, 2 помпон, тегү өчен энә кирәк.

Иң элек башмакның арткы өлешен әзерлибез *(1 нче фото)*. 40 күз җыеп, уңнан 10 см озынлыкта бәйлибез.

Күзәнәкләрне 4 энәгә бүләп, һәр энәгә 10ар күз җыябыз. Шуннан түгәрәк рәтләре буенча уңнан бәйлибез *(2 нче фото)*.

18 см озынлыкта бәйләгәч (чәнти бармак капланырга тиеш), башмакның башына керешәбез *(3 нче фото)*. Моның өчен түгәрәкнең һәр икенче рәтендә күзләрне киметә башлыйбыз: 2 нче күзне төшереп, 3 нче күзне бәйләп алабыз һәм аны төшереп калдырган күз аша чыгарабыз. Шулай итеп, 4 тапкыр күзләрне киметәбез. Шуннан соң инде түгәрәкнең һәр рәтендә күзләрне киметәбез. Һәр энәдә 2шәр күз, ягъни барлыгы 8 күз калгач, күзләрне бергә җыеп тарттырабыз һәм башмакның эчке ягына сүтелеп китмәслек итеп эләктереп куябыз. Энәгә йон җепне саплап, шуның белән укчә өлешен тоташтырабыз.

Икенче сыңарын да шулай бәйлибез. Әзер башмакларны юеш тукыма аша парландырып (үтүкләп), помпон белән бизибез *(4 нче фото)*.

КЕШЕ СҮЗЕННӘН УЙЛАН ҮЗЕҢ ДӘ

Акылы кысканың теле озын, ди халык. Сүз белән терелтеп тә, үтереп тә була. Гөнаһ җыеп та, билгеле. Әйтик, белер-белмәс сүз, тикшерелмәгән мәгълүмат таратып. Заманасы да шундый бит әле аның: акны – актан, караны карадан аерып булмый торган.

Ялган сүз таратуның җаваплылыгы, социаль челтәрләрдә аралашу тәртибе турындагы сорауларга «Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН җавап бирде.

:: Хәзрәт, хәзер аралашуыбызның күп өлеше телефон, социаль челтәрләргә күчте. Телефонда еш кына аралашу төркемнәре (чат) оештыралар. Анда хәбәрләрнең дә төрлесе килә. Кайберләрен, дөресме-юкмы, тикшереп тормыйча, берсеннән икенчесенә җибәреп утыручылар да табыла. Шуннан китә гайбәт, сүз, күпертеп сөйләүләр... Хәбәр ялган булса, гөнаһы тараткан кешенең барысына да төшәме? Кем җавап тотар?

– Хәзер, дөрестән дә, яше дә, карты да телефонда, интернетта утыра. Мәгълүмат тарату мәсьәләсе шуңа да актуаль кала. Үземнең дә күргән бар. «Ватсап», «Телеграм» дигән социаль челтәрләр бар бит. Анда төрле чатлар оештыралар. Туганнарын, дусларын шунда кушалар. Теләсә кая күргән хәбәрне шул чатларга тутыралар. Тикшереп торыш юк – күрдем, ишеттем, сез дә күрегез. Чаттагы башка кешеләр дә, кара әле, шулай икән бит, дип, башкаларга тараталар. Аллаһы Тәгалә дә: «И мөэминнәр, әгәр бер фасыйк сезгә бер хәбәрне китерсә, ул хәбәрне тикшерегез, сездән бер кавемгә зарар ирешмәсен өчен, ул хәбәрне белмәү сәбәпле, әгәр тикшермичә эш кылсагыз, кылган эшләрегезгә үкенүчеләр булып әверелерсез», – ди. Кешеләрнең хәбәрләрне тикшереп тормавыннан пропагандада да файдалана, кызганыч.

Кешегә телефон экранына бер-ике мәртәбә басып алу берни тормый. Әмма шул фетнә чыгарырга бер сәбәп була ала.

Адәмнең (г.с.) Кабил һәм Хәбил исемле ике малае булганы билгеле. Мәгълүм ки, Кабил туганын үтерә һәм дөньяда үтерү гөнаһын үз өстенә алган беренче кеше була. Кабилдән алып дөнья беткәнче күпме үтерү очрагы булса, шул үтерүләрнең гөнаһы Кабилгә булачак. Барысы да түгел, берникадәр өлеше, чөнки ул – бу гөнаһның башлангычы. Сораудагы очракта да шулай. Гөнаһларның күпмедер өлеше беренче булып хәбәрне тараткан кешегә төшәчәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кеше уйламыйча бер сүз әйтергә һәм шул сүзе өчен 70 елга җәһәннәмгә әләгергә мөмкин», – дигән. Сорвыбыздагы мәсьәләгә бик туры килә бит бу. Аллаһ сакласын! Хәзерге заманда – интернет чорында 70 елга җәһәннәмгә әләгү күпкә җиңеләйде.

:: Чатларда фетнә (ыгы-зыгы, талашу) чыгару дини күзлектән шулай ук гөнаһ саналадыр? Кешеләрне бер-беренә каршы капма-каршы куяу бит ул.

– Дини күзлектән гөнаһ буларак санала. Анда бит әле шуңа өстәп гайбәт, кешегә яла ягу ишеләре дә бар. Тормыш шул социаль челтәрдә кайный бит. Гайбәт туган, фетнә чыккан саен, шул аралашу чатын барлыкка китергән кеше дә, шул чатта утырган кешеләр дә гөнаһ ала. Киңәш шул: тузга язмаган, файда китермәгән хәбәрләр булган чатлардан чыгып китегез. Үзегезгә файдасы күбрәк булыр.

:: Интернетта озаклап утырып, юк-бар язышып, кайчак вакытыбыз да бушка уза. Вакыт – кадерле шәйдер. Файдасыз узган вакыт өчен җавап тотасы булырмы?

– Кызганыч, бу – заман чире. Хәдистә дә: «Кеше ике әйбернең – вакыт һәм саулыкның кадерен белми», – диелә. Вакыт – яныйп торган шәм кебек. Бер мәлне, шул шәм эреп беткәч, вакыт та, гомер дә беткәнен чамалыйсың. Безгә кадәр яшәгән

Илдар Мөхәммәтҗанов

галимнәр, динебезнең бөек шәхесләре вакыт кадерен яхшы белгән. Алар Аллаһы Тәгалә биргән гомерне файдалы эшкә багышлаган. Әйтик, дингә, гаиләгә, Аллаһы Тәгалә каршында хезмәт кылуга. Аллаһы Тәгалә әйтә бит: «Сезнең кайсыгызның гамәлләре буенча иң яхшысы икәнен аңлау өчен, без үлемне һәм яшәүне барлыкка китердек». Кеше гомере – гамәл җыю. Аркасында – багаж. Шул багажга яхшысын да, яманын да тутырабыз.

:: Кайбер смс-хәбәрләрдә: «Бу хәбәрне 10 якын кешеңә тарат, юкса сине бәла-каза саклап торыр», – дигән сүзләр дә язылган була. Бу бит инде шулай ук ялган, дөрес түгел...

Санкт-Петербургта яшәүче рус егете Максим Кузнецовның декабрь аенда «Татарский с нуля» исемле дәреслеге дөнья күрәчәк. Күптән түгел яшь галимне Казандагы фәнни үзәккә читтән торып эшкә алганнар. Шул сөенечтән ул «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясенә дә сугылды. 12 тел белгән егет әйтүенчә, аның үзе белгәннәрне башкаларга да өйрәтергә хакы бар.

– Татар теле сиңа кирәк, ә ник татарга кирәкми ул? – дип сорадык Максимнан.

– Тормышта матди якны гына кайгыртып, ашап-эчеп, дөнья куып кына яшәп булмый. Бөтен нәрсәне дә акча белән генә үлчәргә ярамый. Аннан да мөһимрәк тел, мәдәният, гореф-гадәтләр, рухи байлыклар бар. Минем шуларны беренче урынга куюм җитми. Татарстанда телне өйрәнү өчен мөмкинлекләр юк, дип әйтеп булмый. Мәктәптә дәресләр укытыла, КФУда татар теле курслары бар. «Ана теле» онлайн мәктәбе эшли. Сәбәп эзләмәүчеләр, ничек тә булса, җаен табарга тырыша дип уйлыйм. Менә бит мин Санкт-Петербургта яшәп тә өйрәнеп ятам. Әле башкаларны да өйрәтергә җыенам, – диде ул.



Читтә яшәсә дә, Максим, бездәге халыкның үз теленә битараф булу сәбәпләрен аңлап өлгергән. Берәү генә түгел икән. Беренчедән, гаиләдә әти-әниләрнең кызыксынуы юк. Икенчедән, мәктәптә телне өйрәтү программалары нәтиҗә бирерлек итеп эшләнмәгән. Бүлеп бирелгән сәгатьләрне дә файдалы итеп уздырырга мөмкин. Авыр булгач, укучы куркып кала. Өченчедән, җәмгыятьтә дә телгә карата ихтыяҗ булырга тиеш. Ә анысы белән мактана алмыйбыз.

– Әгәр әти-әнинең туган телне өйрәтү теләге булмаса, монда мәктәп кенә булыша алмый. «Туган тел кирәкми» дигән сүзләрне бик авыр кабул итәм. «Әгәр рус телен белмәсә, бала БДИ бирә алмаячак» дигән фикер белән дә килешмим. Ике телне белгән кешегә, киресенчә, чит телне өйрәнү җиңелрәк, – ди яшь галим.

Ә менә Максимга татар теле кирәк. Татарчаны алты ел буе өйрәнә икән. Безнең белән дә әкренләп татар телендә аралашырга тырышты.

– Ык-мык килә дип аптырамагыз. Язу, уку осталыгым бар, тик нишләтәсең, аралашу җитми. Танышларым арасында татарча сөйләшүче булса, мондый проблема тумас иде, билгеле. Тик мин туктап калырга җыенмыйм, татар телен тагын да шомартырга телим, – ди ул.

Максимның Казанга әле беренче генә килүе. Шушы берничә көн эчендә дә ул татар мохитен тоярга, хәтта аны булдырырга да тырышкан. Ничек итеп?

– Беренче «Түбәтәй» кафесына кердем. Анда кассир белән татарча аралаштым. Рус малаеның шулай татарча сөйләшергә тырышуына гаҗәпләнделәр, – дип елмая ул. – Удмуртиягә баргач, удмуртча, Карелиядә фин һәм вепс телендә сөйләшергә тырышам. Татарстанда, әлбәттә, татарча инде! Казанда барыннан да бигрәк борынгы биналар ошады миңа. Өч көнгә килдем бит, шәһәрне белү өчен, атна буе йөрергә кирәк. Токмачлы аш та ашыйсы килә әле.

Сүз аның тиздән бастырылачак китабына килеп җитте.

– Вепс, фин теле буенча үзөйрәткеч бар, хәзер менә татарга да булсын, дидем. Татар, рус, чуаш, удмуртмы, башкасымы – тел белән кызыксынган бар кешегә дә файдалы булыр дип ышанам. Кем теле – шул өйрәнә алыр. Мине каталаулы итеп яза дип шелтәләүчеләр дә бар. Әмма башка галимнәр тагын да каталаулырак яза, – ди ул.

Максим дәреслегенә 2016–2017 нче елларда унике дәрес язган. Аннан текстлар белән тулыландырып, рецензияләү өчен, ике ел элек Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәргән. Хаталарны Татарстан Мәгарифне үстерү институты белгечләре төзәткән.

– Китапның исеме рус телендә. Ул грамматиканы аңлатуга корылган. Анда биремнәр дә, текстлар да, русча-татарча сүзлекләр дә бар. Үзем башка милләт кешесе булгач, башкаларның да татар телен җиңел өйрәнүен телим. Менә шушы максаттан тайпылмаска тырыштым. Дөрес, тәнкыйтьләүчеләр дә булыр. Мин гадел тәнкыйтьне кабул итәргә әзер. Ниятем изге: татар телен өйрәнергә теләүчеләр күп булсын, – ди Максим Кузнецов.

Максимга күп итеп газета һәм китаплар биреп җибәрдек. Үзе сорагач, хәтта аптырап та калдык. Татар кешесенә бушлай газета сузганда ул, кирәкми, дип алмыйча китәргә мөмкин. Максим исә сумкасын тутырды. Сумка түгел, үзе әйтүенчә, букча инде...

Сәрия МИФТАХОВА

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ИЛ УЛЛАРЫ

Исән-сау яшәгән Ватан Геройларының халык, бигрәк тә яшьләр белән аралашуы бүген – махсус хәрби операция барган көннәрдә бигрәк тә кирәк. Бу җәһәттән «Татарстан Геройлары» җәмгыяте рәисе Газинур Хәйруллин инде беренче көннәрдән үк мөрәҗәгать белән чыккан иде.

– Украина минем өчен чит җир түгел. Совет елларында мин хезмәт иткән 175 нче хәрби-транспорт авиация полкы Запорожье өлкәсенең Мелитополь шәһәрендә урнашкан иде. Хәзер ул – ут сызыгында. Бүген без тыныч тормышта яшибез. Татарстанда милләтара һәм динара татулык хакимлек иткәнгә горурланабыз. Мондый вазгыятьнең кешелек өчен ни дәрәҗәдә кыйммәтле икәнлегенә тагын бер кат инандык. Һәр кешенең үзенчәлеген кабул итеп, бер-береңне хөрмәтләп яшәгәндә генә тынычлыкка ирешеп була. Бу – безнең бурыч. Россия Президенты кабул иткән карарларның барысы да уйланылган, тикшерелгән. Безнең көч – бердәмлектә, дуслыкта, бер-беребезне аңлап эш итүдә, – дигән сүзләр бар әлеге мөрәҗәгатьтә.

Хәйруллин Газинур Гарифҗан улына 1996 елның 22 августында Әфганстан территориясендә әсирлектән котылу вакытында күрсәткән батырлыклары өчен Россия Герое исеме бирелә.

Тарих

Бу истәлекле датаның нәкъ менә шушы көнгә туры килүе очраклы гына түгел. Революциягә кадәр 9 декабрьдә Георгий кавалерлары көне билгеләп үтелгән. Ватан Геройлары көнен билгеләп үтү турында карар 2007 елда кабул ителә. «Без моның белән каһарманлык кылган бабаларыбызны искә алып кына калмыйбыз, бәлки Советлар Союзы, Россия Геройларын да хөрмәтлибез», – дип языла әлеге документның аңлатмасында.

Республикабыз бу өлкәдә дә өлгерлек күрсәтә. Советлар Союзы һәм Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан һәм Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалерлары иҗтимагый оешмасы республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев ярдәме белән 1999 елда ук төзелә. Аны оештыру эшендә бер төркем Геройлар – Илдус Мостюков, Борис Кузнецов, Николай Фролов башлап йөриләр.

Беренче корылтай 1999 елның апрель аенда үткәрелә. Ул вакытта республикада төрле категориядәге 120 Герой яши. Алар арасында 9 Советлар Союзы Герое, 3 Дан орденының тулы кавалеры, 3 Россия Герое, 96 Социалистик Хезмәт Герое һәм 9 Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры була. Корылтайда җәмгыятьнең рәисе итеп Илдус Мостюков сайлана.

Корылтайда кабул ителгән уставта бурычлар да тәгаенләнә: Ватан Геройлары батырлыгы үрнәгендә республикада яшәүче яшь буынга патриотик, хезмәт, әхлакый тәрбия бирү, Бөек Ватан сугышы тарихы һәм сугыштан соң илдә халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерү турында-

Илдар Мөхәммәтҗанов

гы ялган мәгълүматларга каршы көрәшү һәм Татарстан Геройларын социаль яклау була ул.

Мостюков Илдус Шәйхелислам улы – Социалистик Хезмәт Герое. Танып белү системалары буенча илебездәге баш институтка нигез сала, аның алыштыргысыз җитәкчесе, генераль конструкторы булып эшли. Галим җитәкчелегендә әле хәзер дә армия һәм флотның сагында торучы Бердәм гомумгаскәри дәүләти радиолокацион танып белү системасы җитештерелә.

Газинур Хәйруллин әйтүенчә, әлеге бурычларны үтәү өчен шактый эшләр башкарыла. Мәктәпләрдә, Суворов, танк училищеларында, техникумнарда, вузларда очрашулар оештырыла. Әле күптән түгел генә ул һәм, Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев батырлыгын кабатлап, үз самолетларына утырып, әсирлектән котылган экипажы Милли китапханәдә яшьләр белән очрашкан. Яшьләр эшләре буенча министр урынбасары Алла Кондратьева анда бик кирәкле сүзләр әйткән: «Мондый чаралар бүген бигрәк тә актуаль. Үз иленең тарихын, геройларын белеп торырга, алардан үрнәк алырга кирәк», – ди ул. Бу чаралар гадәттә Татарстан

«Казан Геройлары» китабыннан

185 татарстанлы Советлар Союзы Герое исеменә лаек була;
12 – Россия Герое исеменә;
134 – Социалистик Хезмәт Герое исеменә;
1 - Россия Хезмәт Герое исеменә.
48 – Дан орденының тулы кавалеры;
5 –Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры.
Барлыгы: Татарстанда туып-үскән **383** кеше.
Тагын **183** татарстанлыга, Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителеп тә, теге яки бу сәбәпләр белән бүләкнең тапшырылмый калуы ачыкланган.
Моннан тыш Татарстанда туып-үсмәсә дә, язмышын республикага бәйләүчеләр, Казандагы хәрби училищеларда, вузларда укучылар, башка төбәкләрдәге милләттәшләребез арасында да Геройлар күп. Барысын бергә кушып санаганда, бу сан **1000**нән артып китә.

Хәрби комиссариаты, төрле министрлыклар, Республика ветераннар советы белән берлектә үткәрелә. Оешма әгъзалары Бөек Ватан сугышы тарихына багышланган конференцияләрдә чыгыш ясыйлар. Патриотик тәрбия өлкәсендә яшьләргә кулланма буларак, Татарстан Геройлары турында китаплар нәшер ителә. Алар арасында 2000 елда Минтимер Шәймиев ярдәме белән дөнья күргән 378 Советлар Союзы Герое турындагы җыентык бигрәк тә зур әһәмияткә ия. Аның белән генә туктап калмыйлар, әлбәттә. Бер-бер артлы Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары, Дан орденының тулы кавалерлары турында китап нәшер ителә. 2008 елда җәмгыять «Бөек Ватан сугышында Татарстан Геройларының җиңүгә керткән өлеше» дип аталган күләмле фәнни-гамәли конференция оештыра. Аның нәтиҗәләре дә халыкка китап буларак тарала. Россия Геройлары турындагы китап исә тарихка яңа чор буларак килеп керә. Әлеге җыентыкны чыгаруга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәм итә.

Россия Геройлары

Сүз дә юк, бүген күбебез беренче чиратта махсус хәрби операция, анда көрәш алып баручы егетләребезнең батырлыгы турында уйлыйдыр. Ил, халык язмышы турында сүз барганда, бу бер дә гаҗәп түгел. Әмма Татарстан Геройлары җәмгыяте Әфганстан, Чечня, Сүриядәге хәрби хәрәкәтләрдә батырлык күрсәткән якташларыбыз, аларның туганнары белән дә тыгыз элемтәдә тора.

ИСАЕВ Олег Николаевич
(Россия Герое исеме, үлгәннән соң, 1996 елның 13 июнендә бирелә)

ГОРИН Виталий Николаевич
(үлгәннән соң, 1997 елның 12 мартында)

КОЗИН Алексей Владимирович
(үлгәннән соң, 1999 елның 12 ноябрендә)

СУПОНИНСКИЙ Александр Анатольевич
(2000 елның 12 мартында)

КОРАБЛЕВ Алексей Михайлович
(2000 елның 28 июнендә)

ӘХМӘТШИН Марат Радик улы
(үлгәннән соң, 2016 елның 23 июнендә)

Татарстанда бердәнбер Россия Хезмәт Герое бар. Ул – Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Беренче Президентыбызга бу бүләк дәүләт һәм халык алдындагы бурычларын үтәгән өчен бирелә.

Махсус хәрби операциядә Россия Герое исеменә лаек булган якташларыбыз:

ГЫЙЛЕМХАНОВ Дамир Рәшит улы
(үлгәннән соң, 2022 елның 25 мартында бирелә)

ИСЛАМОВ Дамир Назир улы
(үлгәннән соң, 2022 елның 25 мартында)

ГАБДРАХМАНОВ Раил Наил улы
(2022 елның августында)

ДОДОСОВ Иван Алексеевич
(2022 елның 28 июлендә).

Сораштыру

Герой кем ул?

Тәэминә БИКТИМИРОВА, тарих фәннәре кандидаты:
– Герой исеменә сугыш вакытында газиз туган җире өчен батырларча сугышкан ир-атлар янәшәсендә 6–7шәр бала белән калган, аларны үстергән, җиңүне якынайту өчен бар көчен куйган аналар да лаек иде. Минем өчен мондый аналар гомерем буена герой булды, әмма, ни кызганыч, дәүләт тарафыннан бу берничек тә бәяләнмәде. Бүген герой исеме минем өчен вакланды, кечерәйде. Элеккеге кебек сокландырмый. Күбрәк пропаганда өчен генә бирелә кебек. Вакыт барган, заманалар үзгәргән саен төрле күренешләргә карашларның да төрлечә булуы, минемчә, бу мәсьәләгә дә кагыла.

Зилә ХӘБИБУЛЛИНА, «Шаян ТВ» алып баручысы:
– Чын герой ул – сугыш кырларында ил өчен башын салган солдатлар гына түгел, ә безнең тормышыбызны көннән-көн яхшырта торган кешеләр дә. Әйтик, укытучылар һәм табиблар. Мин үзем каһарманнарга сокланам һәм үрнәк алам, аларны онытмаска тырышам. Мәсәлән, Юрий Гагарин – үрнәк алырлык шәхес. Бөек Ватан сугышына килгәндә, әлбәттә, фашизмга каршы көрәшкән һәр совет солдаты хөрмәткә ия. Аларның батырлыкларын бәяләп бетереп булмый. Бу кешеләрне 9 Май җиткәндә генә түгел, көн саен истә тотарга кирәк.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

ВАТАН ҺӘМ БУРЫЧ

ЧАЛЛЫ ЭШМӘКӘРЕ РӨСТӘМ ГАТИН ЛИСИЧАНСКИДА ГУМАНИТАР МИССИЯ БАШКАРА

Бу дөньяга килгән һәр кешенең аңа гына хас тормыш фәлсәфәсе буладыр. Көн иткәндә таяна торган кагыйдәсе, дөньяга карашы, йөрәге яткан эше. Әңгәмәдәшебезнең тормыш мәгънәсе – кешеләргә ярдәм итү. Йөрәге яткан эше дә шул. Ил-көн кичергән вакыйгаларга тыныч кына карап утыру мөмкин булмагач, әнә шул тормыш фәлсәфәсенә ышанып, мөһим сәфәргә кузгала да бит ул.

Сүзебез – Чаллы эшмәкәре Рөстәм Гатин турында. Октябрь азагында Татарстан шефлыгында булган Лисичанск шәһәрендә кыр кухнясы оештырырга, халыкны кайнар ризык белән тәэмин итәргә дип китә ул. Хәзер туган шәһәренә ялга кайткан мәле. Монда да көне минуты-сәгате белән алдан планлаштырылган. Барысының да беләсе, аны ишетәсе, тыңлыйсы, күрәсе килә ич! Ике айга якын вакытын шунда үткәргән бит ул.

Соңрак үзе дә әйтер: үлем дә, җимерекләр дә, гомерен куркыныч астына куюда куркытмаган аны. Башта бер генә уй бөтерелгән: эшне тиешенчә оештыра алырмынмы? Сынатмаммы? Юк, сынатмаган. Без аннан ерак юлга илткән ният, Лисичанск шәһәрендәге көнкүреш, ярдәмләшү савабы турында гәпләштек.

Ният турында

Рөстәм Гатин исеме Чаллыда да, Татарстанда да яхшы таныш. Менә инде ничә ел дәвамында шәхси кыр кухнясын оештырып, автокаладагы мохтаҗларны ашату белән мәшгуль ул. Моннан тыш спорт, бәйрәм чараларында да кыр кухнясы оештырып, халыкны кайнар ризык белән тәэмин итә. Коронавирус чорында медицина хезмәткәрләренә дә шундый ярдәм күрсәтәннәр. Аның ризыкларын кемнәр генә авыз итмәгән! Кыскасы, сүзендә дә, йөрәгендә дә – кешеләргә игелек кылу, файдалы булу теләге. Шул теләк хәрби хәрәкәтләр зонасына барырга этәргән аны.

– Мин үзем хәрби хезмәт юлын узган кеше түгел. Бәлки, әнә шул кимчелегем өчен ничек тә файдалы буласым килгәндер. Качып калу ише нәрсәне белмим дә. Мине алай тәрбияләмәделәр! Әйтик, мин компьютерлар яисә аяк киеме тәзәтүче кеше булсам, миннән әллә ни файда булмас та иде. Ә бит минем бер юлы меңәрләгән кешене ашату тәҗрибәсе бар. Көч, мөмкинлекләр була торып, кул кушырып утырасы килмәде, билгеле. Шуңа күрә тәвәккәлләдек. Башта үз көчебез белән генә барырбыз дигән идек, әмма шәһәр хакимияте безнең ниятне хуплап, ярдәм итәргә алынды. Сәфәр бер көнлек кенә түгел бит, берничә айга дип җыенып киттек, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Ният дигәне күңел түрендә күптәннән барлыкка килгән икән инде анысы. Җәй айларында ук.

– Дустым, «Болгар» фонды җитәкчесе Рәшид хәзрәт белән мәчеттән чыгып барабыз. Бер мәлне бер-беребезгә карап куйдык та, бертавыштан: «Донбасска барыргамы әллә?» – дидек. Андагы хәлләрне күптән күреп-ишетеп белә идек инде, – дип сөйләде Рөстәм Гатин.

Хәлләр кискенләшә башлагач, ниятне тормышка ашырырга керешәләр. 24 октябрьдә юлга кузгала алар.

– Бу көнне яхшы хәтерлим, чөнки әтиемнең туган көне иде. Әлбәттә, улы бик үк сөендерерлек бүләк ясамады инде… Тик нишләтәсең? Дөресен әйткәндә, сәфәребез турында безнең якыннарыбыз иң соңгы мизгелдә белде. Шулай дөресрәк тә! Алар безнең өчен артык борчылыр иде. Аннан соң, ниятебез тормышка ашмаса? Анысы да бар бит. Соңрак белгәч, аларның безне бармаска үгетләү мөмкинлеге дә азрак калыр иде. Аңлап кабул иттеләр. Әни улының карарын бик җитди кабул итте, әтигә авыррак туры килде. Билгеле инде: ул бит хезмәт иткән кеше. Аннан, әти ил-көн хәлләрен белә, безнең кая юл тотасыбызны да яхшы чамалый… – ди әңгәмәдәшебез.

Ниятенә күрә чарасы да табыла бит. Рөстәм Гатин һәм аның командасының юлга кузгалуларын ишетүгә, шәһәр эшмәкәрләре дә ярдәм кулы сузарга ашыга. Егетләрне кием-салым, башка кирәк-яраклар белән тәэмин итеп, җылы сүз, хәерле юл теләп озатып калалар.

Сәфәр турында

Ә юл ерак. Сәфәр куркыныч. Ял итәргә бармыйлар бит. Әңгәмәдәшебез үзе дә әйтә: кешеләрне ашату буенча тормышындагы иң зур заказлары бу!

Юлдашың үзеңнән яхшырак булсын, ди халык. Рөстәм Гатин да бу сүзләрнең хаклыгын яхшы аңлый. Аның белән юлга кузгалган командада җәмгысы алты кеше. Сыналган, тик сынатмаган дуслар! Хәзрәт тә бар, алтын куллы оста да, техника белән дус кеше дә, хәтта бокс буенча спорт мастеры да!

– Юлда төрле хәлләр була. Билгесезлеккә киттек бит. Без бер-беребезнең тормышы өчен җаваплы. Шундый командада эшләвемә шатмын. Гомерләрнең кыл өстендә калган мәлләре аз булмады. Кемдер минаны күреп ала да, урап уз, ди, кемдер өстән гранаталы квадрокоптерны күреп ала да саграк булырга куша. Менә шулай эшлибез, – дип сөйли Рөстәм Гатин.

Кирәкле урында кирәкле булдык. Рөстәм Гатин әнә шуңа сөенә. Кыр кухнясында дүрт казан урнаштырганнар. Бер казанда 300 кешелек ризык әзерләргә була. Өстәмә кыр кухнясы куйсалар, якын-тирәдәге шәһәрләргә дә ризык җибәрү мөмкинлеге бар, ди. Рөстәм Гатин һәм аның командасы әзерләгән кайнар ризык һәр кешегә җитә. Бишәр мең кешене ашаталар. Көн саен бу! Хатын-кызлар, балалар, өлкәннәр, йорт-җирсез калучылар, хәрбиләр дә ашарга килә. Администрация, хастаханә хезмәткәрләренә дә кайнар ризык белән булышалар. Кешене аралап тору юк. Бер телем икмәк кемгә дә кадерле һәм кирәк… Сүз уңаеннан, азык-төлек – хәләл. Монысы сәфәргә җыенганда ук оештыручыларның төп шартлары булган.

Шартлар турында

Ризыкка караганда патрон, бомба күбрәк анда, дип уртаклаша әңгәмәдәшебез. Хәрби кием кигән, кулына автомат, хәрби кирәк-яраклар тоткан кешеләрне күрү, әлбәттә, алар өчен дә баштарак ят нәрсә булган, билгеле. Тик кеше нинди шартларга да ияләшә икән ул…

– Без хәрбиләр булмасак та, атыш, шартлау тавышлары астында эшлибез. Салют тавышлары кебек. Әмма ул салют тавышлары беркайчан да тынмый… Бездән хәрби хәрәкәтләр сызыгына – нибары биш чакрым, – ди Рөстәм Гатин. – Бу аңлатып бетереп булмастай куркыныч һәм… кызык. Мин үлемнән дә, башкасыннан да курыкмадым. Эшебезне тиешенчә оештырып булырмы, башкарып чыгарбызмы – менә шул күбрәк борчыды.

Әлеге дә баягы мөһим сәфәрне бергә кичәргә ризалашкан командасына рәхмәтле ул. Алардан башка кыен ашарга туры килер иде. Көн саен иртәнге 4тә торалар, физик күнегүләр, намаз турында да онытмыйлар. Көндәлек шартларыннан зарланмыйлар. Күрше шәһәрдә яшиләр. Татарстан Хөкүмәте бу җәһәттән аларны кайгырткан. Хәл җыеп алырга мөмкинлек бар, дип куана әңгәмәдәшебез. Башкача булса, монда озакка калып булмас та иде…

Ә шәһәр халкының яшәү шартларына килгәндә…

– Шәһәр җимерек инде. Көн саен фильмнарда гына күреп белгән урыннардан узабыз. Әйтерсең лә, декорацияләрне онытып калдырганнар… Хәзерге заманда андый хәлнең булуы мөмкин дә түгел бит югыйсә. Газ, су, ут, инфраструктура, элемтә юк. Утын белән көнгә йә көн аралаш бер су китерү каралган… Шундый шартларда кешеләр көн күрә. Өендә (өй дип әйтеп булса инде) миче булганнарга җиңелрәк, утын белән җылытып була. Анда һава торышы да үзгәрәк. Әйтик, 2–3 градус суык булса да, 10 градуслык салкын кебек тоела, – дип сөйләде Рөстәм Гатин. – Әлбәттә, килгән халык безгә рәхмәт әйтә. Аларга кыен. Күбесен яхшы киләчәккә өмет яшәтә. Таяныч-терәк барлыгын күрү аларга бу шартларны җиңелрәк кичерергә ярдәм итә.

Рөстәм Гатинның шәхси архивыннан

Ярдәмләшү әҗере турында

– Кешеләр, җәмгыять үзгәрде, диләр. Юк, дим. Барысы да тәртиптә. Ярдәм кулы сузар кешеләр, мәрхәмәтле затлар күп! Сорарга да, эзләргә дә кирәкми, алар бар, – ди Рөстәм Гатин. – Горурлык хисләре кичерәбез, әлбәттә. Зур игелекнең бер өлеше булып торабыз бит.

Әңгәмәдәшебездән бу эшләрне нинди максаттан башкаруы турында сорашабыз. Яхшылык эшләүнең әҗерен күрәме ул?

– Иң зур әҗер – минем сау-сәламәт, исән булуым. Син уянган, күзләреңне ачкансың икән, бу инде – бүләк. Аяк-кулың бар, әйләнә-тирәңдә яхшы кешеләр бар икән, моның өчен дә рәхмәтле булырга кирәк. Синең белән дус булырга телиләр, сиңа таяналар, үрнәк итеп күрәләр… Бу әҗер түгелме? Башкарган эшләрнең нәтиҗәсе бит бу.

P.S. Рөстәм Гатин ялдан соң кабат Лисичанскига барырга әзерләнә. Үз чиратыбызда без дә аңа сәфәрендә уңышлар, сәламәтлек теләп калабыз!

АСИЯ ЮНЫСОВА:

«ҮЗ ТАТАРЫҢНЫ ЯМЬСЕЗ ИТЕП КҮРСӘТЕРГӘ ЯРАМЫЙ»

Язучы, журналист Асия ЮНЫСОВАны редакциядә әле дә сагынып искә алабыз. Аның кебек эшләүче башка юк, мөгаен, булмас та. Сүз стиль, тел байлыгы, гыйлем турында гына түгел, хикмәт аның язу тизлегендә дә. Бурандай дулап кайтып керә дә: «Кулдан язарга вакыт юк, әйдә, әйтеп торам», – дип, машинисткалар янына барып утыра. Нәтиҗәдә күз ачып йомганчы тәнкыйть мәкаләсе, я булмаса әңгәмә, я инде очерк туа. Бу юлы без аның белән күбрәк әдәбият хәлләре турында сөйләштек.

:: Журналист һәм язучы. Бер караганда, икесе – ике төрле һөнәр. Язучыга күкләр якынрак булса, журналист – җиргә басып йөри торган һөнәр иясе.

– Мин җиргә басып йөри торган журналист булмаганмындыр инде. Гариф Ахунов та: «Син әдәбиятка – журналистика, журналистикага әдәбият алып килдең», – дигән иде. Ул минем һәр язган мәкаләмне җыеп барган булган икән. Ә Туфан абый Миңнуллин мине берничә җөмләмнән дә тануын әйтә иде. Гади яза белмәдем. Сүзне әйтсәң, хикмәтле әйтергә кирәк. Укучыны һәр язмаң белән баетырга кирәк. Синең мәкаләңне укыгач, аның күңелендә утырым калсын, ул уйланып йөрсен. Әдәби әсәргә алынганда да шулай. Мәгълүматлы булсын дип, энциклопедиядән өземтәләр кертәм. Кеше кулына энциклопедияне әллә ала, әллә юк, миннән укып белеп калсыннар, дим. «Мәк чәчәге» әсәремдә, мәсәлән, танылган рәссам Айвазовскийның әнисе татар булуын искәртәм. Белсеннәр, горурлансыннар! Бөтен җирдә дә татар эзләре бар. Һәр татар хатыны баласын: «Вот серенький волчок, утащит тебя за бочок», – дип тәрбияләми, «Үсеп буйга җитәрсең, мәдрәсәгә китәрсең», – дип, биләүсәдә чакта ук мәгърифәт орлыгы сала.

:: Әнә шулай берәмтекләп җыйган иҗатның кадере бармы соң?

– Минем иҗатымның кадере юк дип әйтергә хакым юк. Чөнки элек эшләгәнемнең әҗерен, халык мәхәббәтен тоеп, татып яшим. Трамвайга утырам икән, һич югы бер кеше таный. Базарга барсам да, һич югы берәр кеше эндәшә. Журналист буларак бәлкем күбрәк таныйлардыр. «Ватаным Татарстан» газетасында ике ел тәрҗемә бүлегендә, 16 ел бүлек мөдире булып эшләдем. Дөрес әйтәсең, рәхәтләнеп, тәмләп язарга вакыт булмады, күбесенчә әйтеп торып эшли идем. Бәлкем, бу – тәрҗемә бүлегендә эшләүдән калган гадәттер. Михаил Горбачевның хакимияткә килгән заманнары, матбугатта тулаем газета битен алып торган чыгышларын тәрҗемә итәргә кирәк. Көн саен бит ул! Баш мөхәррир Сабиров башымнан сыйпый иде инде. Чөнки ул чыгышлар рус газетасы белән бер көндә чыга барды. Русларга әзер килеп төшә ул, ә безгә тәрҗемә итәсе. Моңа чаклы эшләгән тәрҗемәчеләр өлгерә алмаган, күрәсең. Тизлек җәһәтеннән шунда чыныктым мин. Тәрҗемә бит ул – математика. Анда беренче сүзне тартып чыгарырга кирәк. Кирәклесен тартып чыгара белсәң, тәрҗемә тиз бара.

:: Ә менә махсус конкурслар каләм әһеленә иҗади стимул була аламы?

– Каләм әһеленә стимул буларак шул гына калды да инде. Язучы, бу конкурста җиңеп булмасмы, дигән өмет белән яза хәзер. Яза белгәне дә, белмәгәне дә. Күп вакыт шул яза белмәгәне җиңеп тә куя... Кызганыч, бүген язучыларның бер актив төркеме генә яза. Мохтаҗ булганының каләме, бу миңа барыбер мал китерми дип, тик тора. Каядыр эшкә урнашканнарның исә иҗатка вакыты бик чикле.

:: Яхшы әсәр иҗат итү өчен нинди шартлар кирәк?

– Иң беренче язучының биографиясе булырга тиеш. Икенчедән, дөнья күрү кирәк. Өченчесе – язучы гамьле булырга тиеш. Балалар өчен язганда да, тәрбияви момент булу шарт. Шул чакта Жюль Верн кебек кабинеттан да чыкмыйча, маҗаралы әсәрләр иҗат итеп була торгандыр. Пүчтәк сүзләр белән кәгазьне капларга кирәкми. Ә мин сүзләр яратам. Югалган сүзләрне табарга, кире кайтарырга тырышам. «Идегәй» дастанында кулланыштан төшеп калган сүзләр шактый. Мәсәлән, «ләңгәз» (поднос) дигән сүз бар. Аны әйткәндә, җиз чыңлавы да ишетелә сыман. Телне мөмкин кадәр ясалма сүзләрдән арындырып, төркилеге күренеп торган сүзләрне кире кайтарырга иде дә бит. Мин, хәтта әдәбият дәресләрендә бәетләр өйрәнгәнче, дастаннарны өйрәнүне күбрәк кертер идем. Тел һәм сүзгә талымлылык, хөр фикер җәһәтеннән якташларым Миргазиян Юныс, Фәнис Яруллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Рафаэль Мостафин үрнәк. Алар хакында «Безнекеләр» дигән шигырьдә яздым. Шуннан барысы да аңлашыла.

Язучылар дигәннән. «Әдипләребез» дигән китапта күпләр минем язмаларны кулланган. Ни өчендер минем алар турында язуым кирәк булган, ләкин язма авторы мин булу кирәкмәгән. Авторитетлы кешеләрне куйганнар. Мәсәлән, Миргазиян абый турындагы «Биектә калу» дигән язмамның авторы итеп Фәрваз Миңнуллинны язганнар. Мондый мисаллар байтак. Туфан Миңнуллинның тычкан турындагы сүзләре минем хакта әйтелгән инде ул.

:: Без, шартлар дигәндә, рухи якны санап киттек. Ә матди якны алсак? Әллә рәхәт шартларда яхшы әсәрләр туа алмыймы?

– Шәхсән миңа тынлык кирәк. Язганда, тамчы тавышы да комачаулый. Хәзер бөтен шартлар да бар югыйсә, сәламәтлек кенә китеп бара. Озын сүзнең кыскасы, эш шартлары миңа мөһим. Компьютерда яза бару һәм төзәтә бару бик уңайлы. Шартлар булганда бик продуктив эшләп була. Ир-ат язучылардан исә көндәлек тормыш мәшәкатьләрен белмәгән, әсәрен бастыру һәм төзәтүне дә хатыннарына йөкләгәннәре бик продуктив эшлиләр бугай. Мәсәлән, Габдрахман Әпсәләмовны Маһинә ханым нык контрольдә тоткан. Гонорарны алырга да үзе йөри иде. Ул чакта язучы гонорарны гаиләсе белән бишәр ел рәхәт яшәрлек итеп ала иде.

:: Каләм хакының шулкадәр төшүен нәрсә белән аңлатып була?

– Ул чакта тиражлар зур, кәгазь сыйфатсыз да, арзан да иде. Китап тиражы 25 меңгә кадәр икән, язучы бер гонорар ала, 25 меңнән аз гына артып китсә дә, авторга икеләтә түләнә. Ә Шамил Рәкыйпов кебек кешеләрнең китаплары 100 меңгә дә җитә иде. Шуңа күрә алар кооператив фатирларны да иң беренчеләр булып алдылар. Хөкүмәт биргән фатирда гаиләләре белән яшәп, кооператив фатирны иҗат өчен тотучылар да булды. Ә соң дистәләгән иҗат йортлары! Шартлар турында соравыңа да җавап бу.

:: Язучыга шул заман кире кайта аламы?

– Аның өчен татар мәктәбен һәм татар авылын кире кайтарырга кирәк. Минем туган авылым Кызылъяр – Фәнис Яруллинны биргән авыл, Миргазиян Юныс исә – күрше авылдан. Шул авылларда хәзер русча укыта башлаганнар. Чишмәләр саекса, Идел дә кибә. Чишмәләрне сакларга кирәк. Кайсы гына хәрби низагны алма, сәбәп итеп телне кысуны китерәләр. Чөнки тел – изге нәрсә. Ә без юкка чыгу юлын сайлаганбыз, ахры. Ник дигәндә, халыкның үзаңы юк дәрәҗәсендә.

> Мондый шартларда язучы өстендә – икеләтә җаваплылык. Үз татарыңны беркайчан да ямьсез итеп күрсәтергә ярамый. Үз «начар»ыңның да яхшы сыйфатын күрә белергә кирәк.

Әле беркөн «Беренче канал» да Ришат Төхвәтуллинны күрсәттеләр. Аның төрек җырын сайлавын башта мин дә гаеп иттем. Аннары моның үзенә күрә бер хәйлә икәнен аңладым. Ул шул рәвешле үзен татар халкыныкы итеп калдырды. Башкортстаннан дип игълан иткәч, башкортча җырларга тиеш иде кебек. Һәр татар үз милләтен күтәрү өчен эшләргә тиеш. Шуңа мин Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» дигән әсәрен соңгы елларда күтәреп чыгуны да кабул итә алмадым. Онытылган икән инде ул әсәр, онытырга кирәк. Имеш, кеше ашаучылар бездә дә булган.

:: Хатын-кызга иҗатта үз урынын табу авырмы?

– Хатын-кыз – беренче чиратта ана. Ул гаиләне алып баруны, бала тәрбияләүне үзенең изге бурычы итеп ала. Аннан калган вакыт иҗатка бирелә. Мөгаен, шуңа хатын-кыз язучылар сирәк булгандыр. Элек хатын-кызлар балалар язучысы сыйфатында гына күренә иде. Әминә Бикчәнтәева, Дәрҗия Аппакова, мәсәлән. Хәзер хатын-кыз әдәбиятка күпләп килә. Беренче роман язучы Мәдинә Маликова бар, аннары Нәбирә Гыйматдинова да проза өлкәсендә күп эшләде. Нәбирә укучыны китап янында тота алды. Алар Тукай бүләгенә дә ия булдылар. Ә менә дөнья әдәбиятында танылган хатын-кыз әдипләр байтак. Әйтик, «Том агай алачыгы» дигән әсәрнең авторы Гарриет Бичер-Стоу, әсәрләрен Жорж Санд буларак бастырган баронесса Аврора Дюдеван, «Кигәвен»нең авторы Этель Лилиан Войнич, «Унесенные ветром» дигән бер әсәре белән үк танылган Маргарет Митчел.

:: Гаиләдә ир дә, хатын да иҗат юлын сайласа, кайсынадыр талантын корбан итәргә туры киләме?

– Бер-берен аңлап, бер-берсенә терәк булып яшәгән иҗади гаиләләр байтак. Мисалга Ләбибә Ихсанова белән Шәрәф Мөдәррисне, Гариф Ахунов белән Гөлшаһидә ханымны, Мәдинә Маликова белән Әхмәт Рәшитне китерергә була. Бездә бар андый мисаллар, күп булмаса да.

:: Тормыш шигарегез нинди?

– «Гайбәтләрдән өстен кал!» Мин шулай яшәдем дә. Тормыш шундый ул: бүген сине хөрмәт итәм дип өтәләнгән кеше иртәгәсен сиңа этлек эшләргә мөмкин. Әйе, өстен булып калырга кирәк. Каршы җавап бир, дип өстереп торучылар булса да.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Шигърият

Рөстәм САФИН

«ГОМЕР» ДИГӘН АРА

Кара инде, кара!
Ул гел шулай бара:
Көнне көнгә ялгап,
«Гомер» дигән ара.

Юллары маяксыз,
Ә һаман да дәшә:
«Атла минем белән,
Атла гел янәшә.

Курыкма бернидән,
Кил, кулымны бирәм.
Таулардан да биек
Анда үскән чирәм.

Җан өшетсә уең,
Кил, җылыма сыен!»

Пар булганнар очар,
Ялгызларга кыен.

Дөнья үзе шундый,
Ай, Зөһрәгә кара:
Яратканда җиңел
«Гомер» дигән ара.

УЙЛАР БЕЛӘН ЯЛГЫЗЫМ

Я, әйтегез, кая ашыгыйм,
Мизгелләр дә гомер санаса;
Ашыгу да калган чикләрен,
Юк итәргә генә яраса?

Я, әйтегез, нигә сагыныйм,
Сагынудан арып, җан сулса;
Ул үзе дә мине сагынмас,
Үткәннәрем коры сан булса?

Я, әйтегез, бармы ярату
Хыялдагы мәңге, гомерлек?
Еллар аша саклап килгәндә,
Бер караса, җаның эрерлек?

САГЫШЫМ

Нишләтергә сине, сагышым?
Киләсең дә төнгә каласың.
Саркысын дип күңел ярасын,
Кулларыңны иңгә саласың.

Кич, көннәрне инде әйтмим,
Таңнарны да миннән аласың.
Нишләтергә сине, сагышым? –
Яратмыйча янга саласың.

АВЫЛЫМ

Нигә һаман якын соң ул?
Ник җибәрми еллар үтсә дә?
Аны ташлап киткән күперләрне,
Кайтмас инде, диеп, сүтсә дә.

«Туган җирең синең», – дисә
Шул ук юлны бергә үткәннәр,
«Нәрсән калган анда?» – дияр
Нигез сатып бәйрәм иткәннәр.

Үз хәлем – хәл,
сүз китермим,
Нечкә кыллар чорнап орчыкка.
Анда гына көнне каршы алып,
Озатып була кичен офыкка.

МЕҢ ДӘ БЕР КАБАТ

Минем хисләр әле һаман да
Киләләрме кичен, адашып?
Сыеныргa урын тапмагач,
Йөриләрме сиңа ярашып?

Китәр алар, юкка борчымас
Иртәләрең керфек ачканда,
Көн дә төшкә кергән хыяллар
Таң атуга сине кочканда.

Зинһар өчен, кума, үтенәм!
Моңсу миңа алар китүдән.
Килер идем үзем,
адашып,
Туктый алсам сәбәп көтүдән.

ХӘБИР ИБРАҺИМ

КҮГӘРЧЕННӘР

(ХИКӘЯ)

Лилия баласын тимер юл вокзалында каршы алырга тиеш иде. Апасы кичә кичен аңа шылтыратып аңлатты. Мәктәптә икенче сыйныфта укыган Алия җәйге каникулда Чаллы шәһәрендә яшәүче матур апасына (аңа, яратып, шулай эндәшәләр!) берничә көнгә ял итәргә дип киткән иде. Инде менә бүген Казанга кире кайтырга вакыт җитте. Лилиянең бертуган апасының Илшат исемле улы бар, Алия белән алар бик дуслар, кечкенәдән үк бергә аралашып яшәделәр...

Чаллы автобусы кичке бишләрдә килеп җитәргә тиеш. Матур апасы Алияне әнә шул автобуска утыртып җибәрде. Лилия аңардан аның кайчан һәм кая киләсен кат-кат сорады. Апасы: «Биштә... ж-д вокзалда... сиреневый төстә булыр!» – дип, серле генә сөйләнде...

Инде биш булды, алты да булды, җиде, сигезенче китте... Ә автобус юк та юк. Бик нык хафага төшкән Лилия әле монда, әле тегендә тапланды, вокзал каршында торучы халыктан туктаусыз автобус турында сорашты, ләкин беркемнән дә җүнле сүз һәм яхшы хәбәр ишетмәде. Ниһаять, вокзал каршында апасы әйткән сирень төсендәге автобус күренде, баласын көтеп зарыккан ана бар көченә шул якка таба чапты. Акрын гына чайкалган автобус нигәдер туктарга теләмәде, мескен хатын озак вакыт аның артыннан чабып барды. Ул шуны аңлады: автобус вокзал каршына туктарга да уйламый, ә бөтенләй икенче якка, кире якка юл алган иде. Лилия аны светофор каршында туктагач кына куып тота алды. Йөгерә-йөгерә тәмам хәлдән тайган, еш-еш сулыш алган ханымның өзек-төтек сүзләрен шофер егет озак кына аңлый алмыйча торды.

– Сез...нең белән... бер... кечкенә кыз... бар...ды... – дип ярды ханым. – Кай...да соң... ул?

– Автовокзалда калды.

– Ни...чек?!

– Без башта ж-д вокзалда туктарга тиеш идек, – диде шофер, – тик соңыннан безгә туп-туры автовокзалга барырга куштылар. Пассажирларны да шунда төшердем...

Сүз куертып торуның мәгънәсе юк иде кебек: Лилия, урамда такси туктатып, бер вокзалдан икенчесенә китте. Таксистны бертуктаусыз ашыктырды, тегесе дә кимен куймады: мөмкин булганча куды! Тик ул да, тиз чабам дип, кеше таптата алмый бит инде!

Баласына карата үзен мәнсез, кансыз итеп сизгән хатын (гаебе булмаса да!) юл буе үзен һәм дөньясын сүгеп барды. Бала! Әй, Аллам, шунда гына булса ярый инде! Әллә ниткән начар кешеләргә ияреп, әллә кая китеп бармаса ярый! Бер мәртәбә ул чак кына баласын югалтмыйча калды. Ире белән аерылган гына иде әле, бервакыт хастаханәдә шәфкать туташы булып эшләгәндә, алар кызы белән кичкырын өйгә кайтырга чыктылар.

fotokto.ru

Ике смена эшләгән Лилия (ирсез тормыш алып барырга кирәк!) бык нык арыган: кызын юлдан үзен генә чыгарып җибәрде. Дөресе, кызын үзе юлдан җитәкләп алып чыгарга тиеш иде. Ләкин юл чиста, машиналар шактый еракта, куркырлык урын юк иде кебек. Ләкин Алия ярты юлны тәпиләгәч кенә, каяндыр (төркемнән аерылып) бер шашкын машина атылып чыкты. Шул «җен», машинасын акырта-бакырта, алга атылды. Лилия, баласына, тукта, дип кул изәргә өлгерә алмады, каушап калды, ә машина туп-туры бала өстенә килә иде. Бер секунд анда, бер мизгел! Әмма шул мизгел аңа мәңгелек булып тоелды һәм ул, аның уйлавынча, шактый озакка сузылды. «Җен-машина» баланың сандали очыннан гына сыдырып узды, җиле белән баланы тораташ булып катып калырга мәҗбүр итте. Машина узып киткәч, куркыныч узганын аңлаган бала кычкырып елап җибәрде һәм юлдан чыгарга рөхсәт биргәне өчен анасын тиргәмәсә дә: «Син бит миңа үзең рөхсәт бирдең, әни, син әйтмәсәң, юлны чыкмаган булыр идем, мин бит сиңа ышандым, әни!» – дип үксеп-үксеп елады. Аллага шөкер, Ходай аларны шул чагында саклап калды, бәла-каза килмәде. Ә менә бүген, бүген шул ук нәрсә кабатланса, нишләргә?!

Кичке сигезләр җитеп килә. Автовокзал бушап калган. Югалган кызын эзләп, вокзал эчендә чабып йөргәндә һәм автобуслар туктый торган парк аша йөгергәндә, ананың йөрәге чыгардай булып типте. «Кызым, кызым, кайда соң син?» Ай, Алла, бар икән бит Ходай, ул әле аларны ташламаган икән! Лилия аны вокзал буйлап эзләп йөри, ә бала, вокзалдан читкәрәк китеп, ипи валчыкларын асфальт өстенә сибә-сибә, бер эскәмиядә күгәрченнәр ашатып утыра. Анасы шуңа шаклар катты: алар – кызны, ә ул аларны ярата сымак. Алар да – җан ияләре бит, гөрләшәләр үзләренчә, кешеләр кебек үзләре... Иптәш бит алар аңа, дус! Әйе, жәлмени соң аңа матур апасы биреп җибәргән Чаллы батоны, әйдә, ашасыннар, тик ташлап кына китмәсеннәр, шушында янда гына йөрсеннәр. Әнә берсе, олырагы, әрсезләнеп, кулдан ук ашый башлады, нәзек, орчык башын һаман да кызның йомшак учына төртә, әллә уйный, әллә назлана... Белмәссең... Алар бит күпкә мәрхәмәтлерәк, рәхмәтлерәк, ул аларны үзенең якын кешеләре итеп сизә. Күгәрченнәр китмәсеннәр...

Әлегә тиклем тыныч кына утырган, үтеп-сүтүчеләргә сер бирмәгән Алия, әнисен күрүгә үк, үксеп-үксеп еларга тотынды. Олы кешенең килүен өнәмәгән күгәрченнәр башта, куркышып, бердәм рәвешле күккә сибелделәр, тик соңыннан кабат җиргә коелышып, узыша-узыша, бала ташларга өлгергән ипи валчыкларын үзләштерергә ашыктылар...

– Елама, балам, елама, тынычлан, мин килдем...

– Мин сине оныткансың, дип уйладым, әни-и-и...

– Сине оныта аламмы соң инде мин, кызым! Ялгыштым, кичер мине, зинһар, мин бит сезне тимер юл вокзалында көттем, апа шулай дип әйтте, тик ул нигәдер менә монда килгән! Кызым...

– Ие... ә...ни...

– Ант итеп әйтәм: мин сине үзеңне генә беркайчан да, беркая да җибәрмәячәкмен... Ишетәсеңме?! Башка беркайчан да... Без бергә... Гомергә бергә...

Лилия, баласын кысып кочаклап, аңа озак кына тын алырга ирек бирмәде. Аның үзенең дә күңеле кайнаган иде, ул үзе дә туйганчы, күзләренә яшь килүдән туктаганчы елады. Ул атасы ташлаган кыз баланың киләчәге өчен әрнеп-әрнеп елады, булмаган байлыкка кызыгып, ике бөртек хәзинәсен бер мизгелдә югалткан сатлык иренә рәнҗеде...

– Курыктыңмы, балам?

– Ие...

– Әгәр дә мин килмәсәм, нишләгән булыр идең?

– Минме?

– Син, син...

– Кассада утыручы апалар янына кереп: «Миңа хәзер нишләргә, әнием каршы алырга килмәде», – дип әйтер идем. Мине чакыручылар... ие... «Нишләп үзең генә калдың?» – дип сорауччылар булды, тик мин беркемгә дә ияреп йөрмәдем. «Ялгыз түгел мин, әниемне көтәм», – дидем.

Алар, бәхетле елмаешып, караңгы вокзалдан чыктылар. Яңа тормыш ияләре... Күгәрченнәр...

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

5–15 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр

П2435
җомга саны
гадәти бәясе 512 сум 70 тиен
444 сум 54 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
гадәти бәясе 1143 сум 96 тиен
980 сум 10 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+ реклама

Әз-мәз мәзәк

– Үзеңә бәяне куя беләсең син...
– Әйе, әмма сиңа ташламалар каралган.

* * *

Әлифбаны укыгач, башка китапны укыйсым килми. Шул бер үк хәрефләр белән төрле китаплар чыгарып, безне алдыйлар бугай.

* * *

– Күзлек киясеңме?
– Юк.
– Борын өстегездә әзе бар бит.
– Сыра кружкасы эзе ул.

* * *

Ир ул туп сыман. Катырак типсәң, башка капкага китәчәк.

* * *

Олы кешедә шуныси гаҗәпләндерә: ул телефоннан хәбәр яза да, җавапны ун секунд та көтмичә, шундук йокларга ята.

* * *

Матрёшкага карап торам да, размерына карамастан, бөтен хатын-кыз да бер үк икәнен аңлыйм.

Йорт-җир киңәшләре

- Тузан суырткыч эченә хушбуй сибелгән мамык урнаштырсагыз, өйдә тәртип ясаганда тәмле ис чыгар.
- Яшь бәрәңгенең кабыгын тимер губка белән бик тиз чистартып була.
- Кино караганда ашау гадәтегез бармы? Ашау урынына бәйләү эше белән утырсагыз, файдалырак булыр.
- Боз шакмакларын үтә күренмәле итеп катырасыгыз килсә, кайнаган су кулланыгыз.
- Лимон суын сыгар өчен аны кисәргә ашыкмагыз, башта тәгәрәтегез, изегез, аннары, кискәч, суы үзе агып чыгачак.
- Черри помидорларын берьюлы кисәр өчен аларны ике такта арасына кыстырыгыз, пычак белән бер генә тапкыр «вжж» итәсе кала.
- Тортны җеп белән киссәгез, өстендәге рәсемнәре бозылмаячак.



Беләсең килсә...

1 **Симфоник оркестрда дирижер сәхнәгә чыккач, кемнең кулын кыса?**
а) беренче скрипканың;
б) дирижер таягы бирученең;
в) оркестр директорының.

2 **«Ут чәчәге» повестен кем язган?**
а) Гомәр Бәширов;
б) Мөхәммәт Мәһдиев;
в) Гариф Ахунов.

3 **Өчпочмакта 90 градуслы почмак булдыручы якларның берсе ничек дип атала?**
а) биссектриса;
б) гипотенуза;
в) катет.

4 **Иделгә ничә елга кушыла?**
а) 1800;
б) 2600;
в) 3400.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. в); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Сканворд җаваплары

Горизонталь: ябалак, чүлмәк, ИП, алабута, Трамп, таш, Фа, үләт, ре, корт, кий, ат, Әминов, Иж, Монако, Газинур, ару, ара, раунд, итәк, ят, урам, аким, Ёл, Тимершәех, сашими, оран, каралты, Сукре.

Вертикаль: чит, Үргәагар, Утёсов, Чүпрәле, яр, лар, Ким, Урта, шау, Имаметдинов, Мутин, йон, им, яка, вагон, микс, Ка, ау, Азат, проза, Рурк, балык, Ирина, ар, Апуш, Илнат, куәтле, фураж, әни, Сара, ТТ, урак, махмыр.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркаләнгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 382

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+